САБЫРЛЫК СЫНАЛГАНДА

Кеше булып каласы иде

> 4–5

БАЕТМАС, БӨЛДЕРЕР

Яңа закон кабул ителгән очракта, шәхси хуҗалыкларга ни яный?

> 6

ИЛТӨЗӘР МӨХӘММӘТГАЛИЕВ:

«Болай барса, китап укучы, театрга йөрүче калмаска мөмкин»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 27 (28800) | Җомга | 25 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТҮБӘҢ КИТМӘСЕН

ТОРАК БӘЯЛӘРЕ ҮСКӘННӘН-ҮСӘ

Казанда үз куышыңны булдыру өчен 30 елдан артык акча җыярга кирәк! «Авито» порталы белгечләре шундый нәтиҗәгә килгән. Җыйган акчаңа гына фатирлы, йортлы була алмау күптән яңалык түгел анысы. Ипотека рәсмиләштереп, үз куышың өчен ай саен кредит түләп яшәү бездә күптән гадәти күренешкә әйләнде. Әмма соңгы арада күпләргә бу бәхет тә тәтеми башлады. Ник дигәндә, Казандагы фатир бәяләреннән чәчләр үрә торырлык! Банк биргән кредит исә фатир бәясенең яртысын гына капларга җитә.

> 7

Ишетми калмагыз

Әзерлек бара

Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган төп чаралар планы расланды. Премьер-министр Алексей Песошин кул куйган карардан күренгәнчә, республикада 79 чара: фестивальләр, бәйге, конференцияләр үткәрү күздә тотыла. Март аенда Ерак Көнчыгыш, Үзәк Азиянең мөселман илләре һәм Россия төбәкләре композиторлары әсәрләреннән «Мөселман дөньясының заманча музыкасы» дигән концерт үткәрү планлаштырыла.

Исегезгә төшерәбез: мөһим бәйрәмне билгеләп үтүгә әзерләнү инде узган ел башында Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча башланып китте. Июнь аенда Татарстанда тантаналы чараларга әзерләнү һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитеты булдырылды. Россия Хөкүмәте дә шундый комитет составын раслады: аңа Хөкүмәт Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин җитәкчелек итә.

Икмәк пешерүчегә ярдәм

Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы икмәк пешерүчеләргә ярдәм итү өчен җитештерү чыгымнарын каплауга субсидия бирәчәк. Бу хакта авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Оксана Лут Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе утырышында белдерде. Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта икмәк бәяләре усү күзәтелә. «Узган елда без 1 килограмм икмәккә 2 сум түләсәк, быел 2,5 сум бирәчәкбез», – диде Лут.

Хәзер бу җәһәттән карар әзерләнелә. Субсидия төбәкләргә март ахырында килеп җитәчәк.

Табибның хезмәт хакы арткан

Татарстанның дәүләт сәламәтлек саклау оешмаларында эшләүче табибларның уртача хезмәт хакы 78 мең сум тәшкил итә. Сәламәтлек саклау министрлыгының Иҗтимагый советы утырышында шулай дип белдерделәр. Узган елда табибларның уртача эш хакын республикадагы уртача күрсәткечтән ике тапкырга арттыру бурычы куелган. Шулай итеп, 2021 елда аларның уртача хезмәт хакы 78,1 мең сумга җиткерелгән. Бу республикада уртача эш хакына карата 203 процентны тәшкил итә. Моннан тыш быел 1 гыйнвардан медикларның эш хакы тагын арткан. Табиблар һәм шәфкать туташларының окладлары – 5 мең сумга, кыештыручыларныкы 4,6 мең сумга үскән.

Районнарда ни хәлләр?

Питрәч

Көек авылында «Әкият» һәм Богородское бистәсендә «Алтын ачкыч» балалар бакчалары ачылды. Биналар ике катлы, аларда иркен якты бүлмәләр, төсле стеналар һәм шкафлар, йомшак келәмнәр, мавыктыргыч уен зоналары һәм уңайлы караватлар бар. Элек күпләр үз балаларын Казанның шәхси учреждениеләренә йөрткән, мондый мөмкинлеге булмаганнар озакка сузылган декретта утырырга мәҗбүр булган. Богородскоедагы яңа бакчага иске бинадан тәрбиячеләр һәм балалар күченгән. Өстәмә рәвештә балалар һәм педагоглар туплаган. Нәтиҗәдә анда 120 бала йөреячәк. Көек балалар бакчасына 220 бала барачак, ел дәвамында урыннарны тагын 100гә арттыру планлаштырыла. Көектә тагын 1415 бала бакчага чират көтә.
(«Алга»)

Кукмара

Кукмара районының Сәрдекбаш авылында заманча хоккей мәйданчыгы куллануга тапшырылды. Элеккегесе агачтан эшләнгән, мәйданы да кечкенә булган. Ә яңасы пластик бортлы, стандартларга туры китереп, егерме алтыга илле алты метрлы итеп ясалган. Балалар бакчасы мәктәпкә кушылганнан соң бушап калган бина да эшкә яраган: аның бер өлешен спортчыларга киенү-чишенү бүлмәсе итеп үзгәртеп җиһазландырганнар. Биредә мәгариф ветераны Мөзәкир Нәбиев истәлегенә хоккей турниры үткәрелде. Уен нәтиҗәләре буенча Сәрдекбаш командасы беренче урынны алды.
(«Хезмәт даны»)

Түбән Кама

22 февраль сишәмбегә туры килүгә карамастан, бу көнне Түбән Камада 20 пар үз мөнәсәбәтләрен законлаштырырга карар кылган. Районның ЗАГС идарәсе белгечләре билгеләп үткәнчә, язылышуны теркәү өчен гадәттә бу көнне сайламыйлар. Әмма 22.02.2022 елның төп «матур» датасы дип санала һәм яшь парлар бу көн аларга бәхет китерер дип ышана. Башка популяр даталарга килгәндә, белгечләр әйтүенчә, 22 июльдә тагын бер «матур» дата көтелә. Бу датага 20 гариза бирелгән инде.
(e-nkama.ru)

Минзәлә

Коронавируска бәйле вазгыять сәбәпле, вакытлыча ябылып торган әрмән телен өйрәнү буенча якшәмбе мәктәбе якын арада яңадан үз ишекләрен ачачак. Бу хакта Минзәлә районында әрмәннәрнең милли-мәдәни берләшмәсе җитәкчесе Геворг Костандян хәбәр итте. «Безнең планда якшәмбе мәктәбен яңа елдан соң ук эшләтеп җибәрү иде. Әмма билгеле сәбәпләр аркасында мәктәпне бераз соңрак ачып җибәрәбез. Якын киләчәктә балаларыбыз яңадан туган телләрен өйрәнү мөмкинлегенә ия булачаклар. Дәреслекләр, бөтен әсбаплар бар», – диде ул. Моңа кадәр курслар «Одзун» ресторанында алып барылса, хәзер дәресләр район мәдәният сарае базасында уздырылачак.
(«Минзәлә-информ»)

ИКМӘК БЕЛӘН СӨТ БУЛСА...

Район, хуҗалык җитәкчеләренә мактау һәм шелтә сүзләре иң күп эләккән коллегия булды бу. Ел дәвамында тырышып эшләгән, табышларын арттырган, эшчеләренә яхшы хезмәт хаклары түләгәннәр мактадлы, ә терлек санын киметкән, азык әзерләүгә җитәрлек дәрәҗәдә игътибар биреп бетермәгән җитәкчеләргә шелтә тыңларга туры килде. Шулай итеп, республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының еллык коллегиясендә тармактагы күрсәткечләр буенча лидерлар һәм аутсайдерлар ачыкланды.

Хезмәт хаклары

Утырыш башланыр алдыннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе белгечләренә ун автомобиль тапшырды һәм «ТатАгроЭкспо» авыл хуҗалыгы күргәзмәсен карап чыкты. Анысы әле бүген дә дәвам итә.

Утырышта төп доклад белән чыгыш ясаган Татарстан вице-премьеры – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров тагын бер тапкыр 2021 елның аграрийлар өчен уңышсыз булуын билгеләп узды. Узган ел барлык категорияләр буенча тулай продукт 237,2 млрд сумны тәшкил иткән. Әлеге күрсәткечләр Идел буе федераль округында беренче булса да, Россия төбәкләре арасында нибары җиденче баскычка урнашырга гына мөмкинлек биргән. «План буенча без 284 млрд сумнан да ким булмаган нәтиҗәләр күрсәтергә тиеш идек. 47 млрд сум җитмәде. Әлеге акча тармакны алга таба үстерер өчен кирәк иде», – диде Марат Җәббаров.

Узган ел ашлык, яшелчәләр һәм шикәр чөгендерен җыеп алуда югалтулар булса да, сөт җитештерү буенча позицияне саклап калуга ирешелгән. Ә йомырка җитештерүдә сизелерлек алга киткәнбез.

– Узган ел без 138 млрд сум акча эшләдек. Авыл хуҗалыгы оешмаларының рентабельлеге, субсидияләрне искә алып, 11,6 процентны тәшкил итте. Моңа без 2020 елдагы ашлык запасын яхшы бәядән сатып ирештек. Ел дәвамында терлекләргә узган еллардагы арзанлы ризык ашаттык. Быел яңа уңыш алганчы андый мөмкинлек юк. Хәлләр бәяләр арту белән дә катлаулыланды. Ашлык кушылмаларының уртача бәяләре аерым позицияләр буенча хәтта 50 процентка кадәр артты, – диде министр.

Коллегиядә авыл хезмәтчәннәренең хезмәт хаклары, районнарда акча эшләү мәсьәләсенә кат-кат басым ясалды. Марат Җәббаров сүзләренә караганда, авыл хуҗалыгында уртача хезмәт хакын 5 процентка күтәрергә планлаштырылган булган. Чынлыкта 24 процентка арттыра алганнар. Быелга да бурычлары зурдан: республикадагы уртача хезмәт хакыннан 80 процентка күтәрүгә ирешмәкчеләр. Иң зур хезмәт хакларын Яшел Үзән, Тукай, Мамадыш, Мөслим, Буа һәм Тәтеш районнарында алалар икән. Әлеге районнар халкы уртача район дәрәҗәсеннән югарырак хезмәт хакы алып эшли. Ә менә Әгерҗе, Яңа Чишмә һәм Баулыда яшәүчеләрнең хезмәт хаклары уртача республика дәрәҗәсеннән 40 процентка кимрәк.

– Хәтта бер районда яшәүче эшчеләрнең хезмәт хаклары 1,5–2 тапкырга аерыла. Бүген авылда кешеләрне 15–20 мең сум акча белән тотып калып булмый, – диде министр. – Безнең әлегә бер эшчегә 700 мең сумнан да азрак керем алучы хуҗалыклар бар. Мондый аз күрсәткеч белән айга 30 мең сум түләү мөмкин түгел. Хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга кирәк.

Чагыштыру өчен, узган ел республика буенча 1 эшченең хезмәт җитештерүчәнлеге 2,8 млн сумны тәшкил иткән. Югары технологияләр кулланып эшли торган компанияләрдә ул күрсәткеч кеше башына 9 млн сумга җиткән, ә уңышлы агрофирмаларда 5 млн сумнан артып киткән. Бу уңайдан министрның мактау сүзләре Әтнә районының «Таң» хуҗалыгына барып ирешә. Алар елына 561 млн сум табыш алуга ирешкән, шуның 76 проценты сөт җитештерүдән кергән.

Соңрак үз чыгышында хезмәт хаклары мәсьәләсенә Президент та тукталды.

– Хезмәт хакы авылда эшләр өчен стимул булып тора. Кызганычка, әлегә авылда хезмәт хакы аз. Ләкин кешеләр бит акча эшләргә тиеш. Авылда эш җитәрлек, ә хезмәт хаклары – айга 20–25 мең сум. Бу мәсьәләнең кадрлар кайту, белгечләрнең сыйфаты белән бәйле икәнлеген аңларга тиешбез, – диде ул.

Һава торышы гына гаепле түгел

Билгеле булганча, авылда тормыш шартларын яхшырту буенча тырышып эшли торган районнарның ел саен рейтингы төзелә.

tatarstan.ru

Быел да Тукай, Әтнә, Балтач, Саба, Буа һәм Кукмара районнары лидерлар рәтендә. Алар терлекчелектә дә, игенчелектә дә башкаларга караганда югарырак күрсәткечләргә ирешә. 2020 ел белән чагыштырганда Мамадыш, Алабуга һәм Чистай районнары да күрсәткечләрен яхшырта алган. Тулай продукт бәясе күрсәткечләре буенча, корылык булуга карамастан, Әтнә, Тукай, Саба һәм Кукмара районнары яхшы нәтиҗәләр биргән. Сөт савып алуда да моңа кадәр телгә алынган районнар мактадлы. Алар – Саба, Мамадыш, Кукмара һәм Балтач районнары.

Шул ук вакытта Татарстанның унбиш районында соңгы елларда бер терлекчелек комплексы да төзелмәгән. Аларда 2021 ел дәвамында бер сыерга уртача савым нәтиҗәлелеге 5 мең килограммнан түбән. Болар – Лаеш, Әгерҗе, Ютазы, Әлки, Яшел Үзән, Лениногорск, Менделеевск, Кама Тамагы, Кайбыч, Яңа Чишмә, Баулы, Чирмешән, Чистай, Спас һәм Апас районнары. Марат Җәббаров әйтүенчә, бу районнар терлек тоту һәм ашатуның автоматлаштырылган технологияләрен кулланмый, аларда терлек азыгы үзәкләре дә юк. Ә бит авыл хуҗалыгы тармагы керемeнең 70 процентган артыгы терлекчелек продукциясен сатудан керә.

– Барлык хуҗалык җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәм: агробизнестагы уңышсызлыкларыгызны һава торышына сылтаудан туктагыз. Реаль нәтиҗә бирә торган технологияләр кулланыгыз. Алдыңгы хуҗалыкларга барып, аларның эш тәҗрибәсен өйрәнегез, – дип шелтә белдерде министр артта баручы район һәм хуҗалык җитәкчеләренә.

Бурыч – ким дигәндә 4 млн тонна ашлык

Коллегиядә Мәскәү кунагы – Россия авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Оксана Лут та катнашты. Ул Татарстанның җиңел сәнәгатьтә алдынгы төбәк булуын һәм федераль ярдәм күрсәткәндә республиканың өстенлеккә ия булуын ассызыклады.

Утырыш ахырында Рөстәм Миңнеханов шәхси хуҗалыкларны үстерү белән кызыксынмаган, бер фермеры да субсидия алмаган районнарны әйтте. Алар – Әлмәт, Теләче, Әтнә, Зәй, Баулы районнары.

– Эре, урта хуҗалыкларда бардыр, аңлыйм, ләкин алар да – безнең кешеләр, без кулланырга тиешле мөмкинлекләр. Муниципалитет, авыл хуҗалыгы идарәләре башлыкларын моңа игътибарлы булуын сорыйм, – диде ул.

Чыгышының ахырында исә быелгы уңышка зур өмет баглавын һәм 4 млн тоннадан да ким булмаган күләмдә ашлык җыеп алырга кирәклеген белдерде. «4 млн тоннадан да ким булмаган күләмдә ашлык җыеп алу бурычын куябыз, – диде ул. – Бу ким дигәндә шулай. Әгәр барлык технологияләрне һәм агротехник вакытларны сакласак, мондый планны башкарып чыга алабыз. Кайбер хуҗалыклар 40–50 процент рентабельлек белән эшләде». Шулай ук сөт җитештерүне 2 млн тоннага җиткерү бурычын куйды.

Президент бүген аграрийлар алдында торган төп бурыч язгы кыр эшләренә әзерлек булуына басым ясады. Кыска вакыт эчендә машина-трактор паркын әзерләргә кирәклеген әйтте.

– Соңгы ике елда без 7 мең яңа техника сатып алдык. Һәм бу эш дәвам итә. Заманча техника кыска вакыт эчендә кыр эшләрен төгәлләргә мөмкинлек бирүенә ышанам, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН – ЮГАРЫ БҮЛӘК

Россия Президенты Владимир Путин Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановны II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләде. Бу хакта Указ хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында пәйда булды.

«Татарстан Республикасының Социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә», – диелә РФ Президентының «Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре турында»гы Указында.

ЧИКЛӘНЕП ЯШӘМӘСЛӘР

mchs.gov.ru

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хәбәренә караганда, Донецк һәм Луганск республикаларыннан эвакуацияләнгән халыкны урнаштыру өчен илнең 47 төбәгендә 58 мең кешелек урын әзерләнгән

Татарстан әзер. Мәгълүм булганча, республика Донецк һәм Луганск өлкәләреннән эвакуацияләнгән кешеләрне каршы алырга җыена. Татарстан бер меңләп кешене вакытлыча эшле-ашлы итәчәк. Аларны кайда урнаштырачаклар, ничек ярдәм итәчәкләр?

Сүз уңаеннан, Донецк һәм Луганск өлкәләреннән күченүчеләрне 23 февральдә үк көткәннәр иде. Соңрак аларның килүен кичектерделәр. Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова аңлатканча, эшелоннарны төрле төбәкләргә җибәрү эше белән кыен хәлдә калганнарны кабул иткән өлкә шөгыльләнә. Бу Татарстан вәкаләтендәге эш түгел.

– Республиканың, Татарстан Хөкүмәтенең максаты – теләсә кайсы мизгелдә шушы кешеләрне каршы алу һәм аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү, – диде Лилия Галимова.

Татарстанда эвакуацияләнгән кешеләргә ярдәм күрсәтү буенча сорауларны хәл итү өчен махсус оператив штаб булдырылды. Утырышларда штаб тарафыннан Донецк һәм Луганск өлкәләреннән күченүчеләргә булышу турында фикер алыштылар. Ә ул төрле яклы булачак.

1 мең кешене Татарстан шифаханәләренә урнаштырачаклар. Анда аларны кайнар ризык, урын-җир белән тәэмин итәчәкләр. «Ливадия» – 150, «Васильевский» – 100, Чаллының «Жемчужина»сы 250ләп кешене кабул итәргә әзер. Моннан тыш кыен хәлдә калучылар «Санта», «КамАЗ», «Кварт» кебек биналарда сыену табачак. Эвакуацияләнүчеләрне вакытлыча яшәү урыннарына махсус автобусларда илтәчәкләр.

Мәсәлән, кыен хәлдә калганнарны «Ливадия» шифаханәсенең «Рябина» дигән корпусы көтә. Биредә барлык шартлар тудырылган, ике кешелек бүлмәләр бүлеп биреләчәк. Шифаханәгә килүгә, медицина белгечләре аларга коронавируска каршы экспресс-тест оештырачак, сәламәтлеген тикшерәчәк. Вакцина ясату да мөмкин. Ихтыяҗ туган очракта, психолог ярдәме дә күрсәтеләчәк. Күчеп кайтучыларның көнкүреше һәм ялы шифаханәдә ял итүчеләрнекеннән аерылмаячак. Анда хәзер барлыгы 81 кеше дәвалана. Читтән килгән кунаклар да чикләнеп яшәмәсләр, ди биредәгеләр. Дүрт тапкыр ашату каралган, балалар өчен уен мәйданчыклары, китапханә бар.

> **Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты:**
> – Килеп туган мондый шартларда бөтен җәмгыятебезне бер йодрыкка тупларга, бердәмлек күрсәтергә, ил җитәкчелеге кабул иткән карарны хупларга, республиканың барлык системалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итәргә тиешбез. Илебез алдындагы кыенлыкларны бергәләшеп хәл итә алачагыбызга ышанам.

Сүз уңаеннан, ашыгыч ярдәм таләп ителсә, республиканың әйдәп баручы хастаханәләре булышырга әзер. Донецк һәм Луганск Халык Республикаларыннан күченеп килергә мәҗбүр булган кешеләрне ашыгыч ярдәм бригадалары каршы алачак, коронавируска каршы экспресс-тест оештырылачак. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, республикада вакцинация уздыру өчен мөмкинлекләр җитәрлек.

Күченеп килүчеләргә эш тә тәкъдим ителәчәк. Мисал өчен, республика оешмаларына 53 меңләп эшче таләп ителә. Тәкъдим ителгән урыннардагы хезмәт хакы – 40 мең сум.

Моннан тыш, Донецк һәм Луганск өлкәләреннән күченүчеләрне сим-карта белән тәэмин итү ниятләнә.

Инде хәбәр иткәнебезчә, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы бүлекчәсе дә гуманитар ярдәм җыюны оештырып җибәрде. Партиянең төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин исеменнән республиканың 20ләп оешма-предприятиесенә хат җибәрелгән. «Бердәм Россия» вәкилләре акчалата да ярдәм күрсәтәчәк. Бу эшкә «Яшь гвардия» дә кушылды.

Теманың дәвамы 4–5 битләрдә >

Дуслык һәм бердәмлек хакына

Билгеле булганча, Казан 2022 елда Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр башкаласы дип игълан ителде. Әлеге статуста Татарстан башкаласы нинди кунаклар кабул итәр? 2022 елда нинди чаралар булыр дип көтелә? Бу хакта Хөкүмәт йортында узган брифингта сөйләделәр.

«ИХОның Яшьләр башкаласы» исеме 2016 елдан бирле бирелә. Моңа лаек булу өчен махсус бәйгедә җиңү яулау зарур. Төрле елларда әлеге дәрәҗәгә Истанбул (Төркия), Шираз (Иран), Путраҗая (Малайзия), Фес (Марокко), Доха (Катар), Дакка (Бангладеш) ия булды. Быел исә бу мәртәбәле исемгә Татарстан башкаласы лаек дип табылды.

Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр форумы җитәкчесе Таха Айхан сүзләренчә, әлеге проект яшь буын һәм, гомумән, Татарстан өчен яңа мөмкинлекләр ачачак. «Әлеге программа кысасында узачак чаралар яшьләр тормышының бар өлкәләрен дә колачлар дип көтелә. «Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр башкаласы» проекты инде менә алты ел дәвамында уңышлы башкарыла. Шуңа да аның кысасындагы чараларның 2022 елда Россиядә уздырылуы биредәге яшьләргә дөньяның 56 илендә яшәүче яшьтәшләре белән танышырга, аралашырга, бәһасез тәҗрибә тупларга мөмкинлек бирәчәк. Моннан тыш, «ИХОның Яшьләр башкаласы» статусы Казанга төрле халыкара оешмалар белән элемтәләр булдырырга, башка илләр белән хезмәттәшлекне ныгытырга ярдәм итәчәк», – диде ул журналистлар белән очрашуда.

Мартта Мәскәүдә узачак тантанада «ИХОның Яшьләр башкаласы» статусы белән бергә Казанга моны раслаучы алтын ачкыч та тапшырылачак. Ниятләр турында Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов сөйләде. Аның сүзләренә караганда, чараларның барысы да дуслык һәм бердәмлек хакына уздырыла. «Безнең уйлавыбызча, «Казан – Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр башкаласы» исеме астында узачак чаралар халыкара элемтәләрне һәм хезмәттәшлекне ныгытырга сәләтле. Шуңа да без ниятләгән эшләребезне тулы күләмдә башкарып чыга алырбыз дип өметләнәбез», – диде министр.

Журналистлар белән очрашуда иң әһәмиятле 10 чарага тукталдылар. Әйтик, «Казан – ИХОның Яшьләр башкаласы» проекты кысасында һәм Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлап, Казанда Коръән сүрәләрен яттан укучылар арасында бәйге оештырылачак. 27–30 мартта узачак бәйгедә 18–30 яшьлек егет һәм кызлар катнаша алачак. Аларны халыкара дәрәҗәдәге жюри, шул исәптән Россия вәкилләре бәяләячәк. Бәйге ике номинациядә үткәрелә, аларның һәркайсында җиңүче 10 мең доллар алачак.

Майда исә ИХОга караучы 56 илдән чакырылу 200 делегат катнашында Казан Яшьләр саммиты узачак. Шулай ук Татарстанда «Казан – ИХОның Яшьләр башкаласы» дип аталучы марафонга старт бирелгән. Марафон барышында мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында белем алучыларга 50 презентация тәкъдим ителәчәк. Шулай ук 30 презентация федераль мәйданчыкларда урнаштырылачак. Нәтиҗәдә 1 млн кулланучыны җәлеп итәргә исәплиләр. Әлеге презентацияләрнең максаты – «Казан – ИХОның Яшьләр башкаласы» проектларына волонтерлар, катнашучылар, амбассадорлар җәлеп итү.

Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының Яшьләр форумы президенты Таха Айхан Татарстан Президенты белән дә очрашты. «Әлеге чаралар яшьләребезгә үз-үзләрен күрсәтү өчен яңа мөмкинлекләр тудырачак, шулай ук Ислам дөньясын Татарстан һәм Казан белән аның мәдәни һәм милли күп төрлелегендә таныштырырга мөмкинлек бирәчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әйтеп кенә бактым

Ялкаулык

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бу коронавирус зәхмәте аралашуларны киметте. Барасы җиреңә барып, кайтасы җиреңнән кайтып булмый. Өйдә ятып, ялкаулыкка чыгып бетмәм микән, дип шикләнә дә башладым. Бөтен юаныч – телевизор. Бер уйлаганда, язасыларым да күп, әмма кулга каләм алып, өстәл янына утырырга да ирендерә башлады. Нужәли картайдым инде?!

Миңа хатынның мөнәсәбәте дә үзгәрде кебек, әледән-әле күзенең агы белән карап алгалый башлады. Кайчак йөзенә сөйкемлелек билгеләре чыгарып, йомшак кына тавыш белән: «Иртән эшкә чыгып киткән ир матур инде ул, име!» – дип әйткәли. «Дөньялар бераз тынычлансын инде, вирус бик котыра бит», – дип аклангандай итәм. Ә ул: «Өйдә язып утыр!» – ди.

Менә утырам, әмма башка бернинди дә уй керми. Кергәли үзе, әмма үземә кызык тоелмый, миңа кызык булмагач, укучыга да ошамаячак бит инде ул! Телевизор пульты төймәләренә баскалап утырганда, экранга Разил Вәлиев килеп чыкты. Аның белән кызыклы әңгәмә бара иде. Дәүләт, җәмәгать эшлеклесе, халык шагыйре төрле җаваплы вазыйфалар башкаруын, озак еллар Дәүсовет комитетын җитәкләвен әйтте дә: «Төрле вазыйфалардан котылгач, иҗат белән шөгыльләнергә вакыт була башлады», – диде. Әйе, дистә еллар буе дәүләт, җәмәгать эшләре белән шөгыльләнгән шагыйрьгә каләм тибрәтергә вакыт калмавы табигый инде ул, ә менә 75 яшьтән соң иҗат өчен вакыт була башлавына шатлануы сәер тоелды. Чөнки бу яшьтә шагыйрь-язучыларның күбесе язудан туктый. Тапшыру тәмамлангач, үзенә шалтыраттым. Һаман да язарга ашкынып торуына соклануымны әйттем дә зарланырга тотындым. «Вирустан куркып, өйдә ята-ята баш та эшләми башлады, тәмам ялкаулыкка чыгып бетәм бугай инде», – дидем.

Иң әүвәл Разил: «Элек башың эшли идеме соң?» – дип шаяртып куйды. Төрттереп берәр сүз әйтмәсә, Разил була алмый кала бит. Аннан соң: «Беләсеңме, ялкаулык – зур нәрсә ул, кешелек дөньясы ясаган бөтен ачышлар ялкаулык, иренү белән бәйле. Кеше җәяү йөрергә иренә башлаган да тәгәрмәч уйлап тапкан. Аннан соң арба ясап, ат җигә башлаган, аннан соң машиналар, пароходлар, самолетлар уйлап тапкан...» – дип тезә башлады. Шул вакыт минем күңел күтәрелеп китте, баш та эшли башлады. И-и тотындык ялкаулык белән бәйле ачышларны санарга!

Разил: «Су ташырга иренеп, безнең эрага хәтле алтынчы гасырда ук кешеләр су торбалары суза башлаганнар. Унтугызынчы гасыр башында немецлар ике көпчәкле самокат ясаган. Тагын бер немец – Филипп Райс исемле бугай, дуслары, танышлары, туганнары янына барып йөрергә иренеп, телефон уйлап тапкан», – ди. Минем дә сер бирәсе килми. «Ньютон, башына алма төшеп, җирнең тарту көче турында ачыш ясаган. Әгәр берни дә эшләмичә, ялкауланып, алмагач төбендә мәлҗерәп утырмаган булса, кешелек шундый ачыштан мәхрүм калган булыр иде», – дидем. Каткат чәй кайнатырга иренеп, Шотландия галиме Джеймс Дьюарның термос уйлап табуын да искә төшердем. Бер-беребезне уздырып, ялкаулыкның бөек сыйфат икәнлеген дәлилләүдән күңелләр күтәрелеп китте.

Менә бит язар өчен тема да табылды. Ялганлый белеп ялганлау – үзе дә Ходай биргән бер сыйфат, ахрысы. Шунысы гына уйландыра: нигә күп ачышлар чит илдә ясалган икән? Моны Разилгә дә әйттем. Ә ул: «Без – бик тырыш, эшчән халык, шуңа күрә юк-бар белән баш катырырга вакыт калмагандыр», – дип, тагын көлеп куйды. Ни әйтергә теләгәнен артык төпченмәдем. Хәер, моның кирәге дә юк иде. Иң әһәмиятлесе, уйландыра бит!

КИТМӘСЕН ҖАНЫЕМ ДОНБАССКА

Пәнҗешәмбе таңы хәвефле атты. Россия Президенты Владимир Путин Мәскәү вакыты белән 5.30да, Донбасс республикаларының ярдәм сораган мөрәҗәгатьләренә җавап итеп, Украинаны «коралсызландыру (демилитаризацияләү) һәм нацизмнан азат итү өчен» махсус хәрби операция башлавы хакында игълан итте.

Минобороны.рф

Мондый хәлнең котылгысызлыгы алдан мәгълүм иде инде. Башында АКШ торган Төньяк Атлантик Блок (НАТО) Мәскәүне бу адымга күптән этәрә инде. Укучылар аптырар, бәлки, Байден да, Макрон да, башка держава лидерлары да Мәскәүне һөҗүм итмәскә өндиләр бит, диярләр. Без публикага ясаган чыгышларны гына күрәбез, сәхнә артын күрмибез. Вашингтоннан инде сугышның датасын берничә тапкыр билгеләделәр, вәләкин Кремльдә сугыш башламаячакларын кат-кат ассызыкладылар. Россиянең АКШтагы илчесе Анатолий Антонов берничә көн элек кенә CBS телеканалына биргән әңгәмәдә: «Мин расларга телим: Донбасс һәм Луганск – алар Украина җире», – дип әйткән һәм һөҗүм турында сүз дә була алмавына ышандырган иде. Ул әңгәмә суынып та бетмәде, Кремльгә әлеге ике төбәкнең бәйсезлеген танырга туры килде. Моның өчен җирлек бик авырлык белән һәм ашыгыч әзерләнде. Тагын искә төшерик: Путин үзе дә Дәүләт Думасының бәйсезлекне тану турында мөрәҗәгатен кире какты башта. Әмма халыкара лидерлар клубы күптән инде Россия җитәкчелегенә сайлау мөмкинлеге калдырмады.

Авторның субъектив фикере дип кабул итә аласыз моны, әмма ул фактлар белән раслана. Көнбатыш лидерлары, әгәр теләсәләр, Мәскәүне куркыныч адым ясаудан туктата алалар иде, НАТО блогы белән көчләр чагыштырмасы Россия файдасына түгел. Моны Путинның үзенең дә берничә тапкыр әйткәне бар. Әмма Вашингтон сугышка катышмаячакларын әйтеп, Мәскәүне даими тынычландырып, котыртып килде. Россия җитәкчелеге үз алдына нинди бурыч куелуын яхшы аңлый иде, әмма аны үтәргә озак вакытлар кыюлыгы җитмәде. Ышанмасагыз, Куркынычсызлык советы утырышында Тышкы разведка идарәсе директоры Нарышкин әфәнденең үзенә сүз бирелгәч, ничек каушавын һәм тотлыгуын карагыз. Владимир Владимирович үзен кыюрак тота, билгеле, вәләкин аңа да рәхәт түгел. Мәскәүнең вазгыятькә карашлар эволюциясе ничек үзгәрүеннән дә аны сугышка этәрүләрен аңлап була. Башта Донецк һәм Луганскиның бәйсезлеген тану белән котылырга теләделәр. Бәйсезлек аларның гамәлдәге чикләрендә генә булуын ассызыкладылар. Аннан Донбасс республикаларының зуррак мәйданда булырга тиешлеген искә төшерергә мәҗбүр иттеләр. Һәм инде, ниһаять, бөтен Украина чиген диярлек иңләп махсус хәрби операция игълан итәргә туры килде.

Россия Президенты Украина хәрбиләрен корал ташларга һәм өйләренә кайтып китәргә өндәде. Бу таләпне үтәүчеләр сугыш барган урыннардан тыныч кына гаиләләренә кайтып китә алачак. Кан коелган очракта исә бөтен җаваплылык Украинада идарә иткән хакимият өстендә булачак, диде Путин. Украина халкына мөрәҗәгать итеп, Президент Россиянең бу адымын килечәктә тагын да куркынычрак вазгыятьне булдырмый калу белән аңлатты. «Безнең Украина территорияләрен яулап алу планы юк», – диде ул.

Пәнҗешәмбе иртәсендә ясаган мөрәҗәгатендә Путин чит илләрне вакыйгага тыкшынудан кисәтте: тарихта күрелмәгән җавап бирелячәген әйтте. Ил лидерлары үзләрен мине болайрак тоталар. Әрдоган Путинга шалтыратып, һөҗүм белән килешмәвен әйтте. Байден тукталырга куша һәм санкцияләр белән яный. Доллар йөз сумны иртән үк узып китте инде. Мәскәү биржалары ачылмады. Финляндия Президенты Россия гамәлләренең Украинага каршы булуын, әмма бөтен Европадагы куркынычсызлыкка янавын билгеләде. Бөекбританиянең оборона министры Уоллес: «Шотланд гвардиясе патша Николай Інең арт сабагын Кырымда 1853 елда укытты. Без моны тагын кабатлый алабыз», – дигән белдерү белән чыкты. Көнбатыштагылар хәрби операцияне туктатуны таләп итә, санкцияләр белән куркыталар. Визаларны юкка чыгарырга, мөнәсәбәтләрне өзәргә өндиләр. Кызганыч, килешү юлларын эзләргә тәкъдим итүчеләр генә күп түгел. Ә утырып сөйләшергә барыбер туры киләчәк. Корал куллануның әле беркемгә дә файда китергәне юк.

Без нәрсә эшли алабыз соң? Куркыныч вакыйгаларны куркып күзәтүче гади халыкның теленнән төшми бу сорау. Иң мөһиме, кеше булып калырга тырышасы иде. Коткы тарату ракеталардан да куркынычрак булган заманда яшибез чөнки.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәренең Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге Советы рәисе **Петрушин** Юрий Иванович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың сайлау системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаре **Борисова** Надежда Петровна; халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә өлеш кертүе, актив иҗтимагый һәм хәйриячелек эшчәнлеге өчен «Әнгам» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Миңнуллин** Әнвәр Габбаз улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Хаҗиев Сафуан Мәхәсим улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Хаҗиев** Сафуан Мәхәсим улы; «Ирек» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе **Хаҗиев** Рөстәм Рәхим улы; «АКТАНЫШАГРОПРОМСНАБ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шәехов** Шәйхенур Тимербай улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен «Айдар» театр-студиясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Галимов Айдар Гани улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Ермакова** Ольга Михайловна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

САБЫРЛЫК СЫНАЛГАНДА

ТЫНЫЧЛЫКНЫ һӘМ АКЧАНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Шатлык күрсәң, очынма, кайгы күрсәң, пошынма, дигән борынгылар. Илдә, дөньяда барган вакыйгаларга битараф калып булмый, әлбәттә. Әмма артык хисләргә бирелү дә яхшыга илтми. Белгечләр дә шулай дип кисәтә.

pixabay.com

Психологик халәт

Ил-көндәге вакыйгаларга һәркемнең йөрәге үзенчә сызлый. Берәүләре салкын акыл саклаа, икенчеләр коткыга бирелеп, бөтеннәрне дә үзләре белән ияртә. Курку, борчылу хисләреннән ничек котылырга? Даруларсыз гына тынычланып буламы?

Психолог Галия ГЫЙМАДИЕВА белән шул хакта сөйләштек.

1. Ни өчен кеше коткыга бирелә? Моның сәбәпләре нәрсәдә?
Баш мие шундый кызык инде ул. Аның бер өлеше һәрдаим әйләнә-тирәдәге хәлне күзәтеп тора. Яшәү өчен куркырлык сәбәп бармы? Ниндидер янау, һөҗүм юкмы? Ул әнә шуларны тикшерә. Билгеле, бар дип күрсә, организмда биохимик процесска башлангыч бирә, курку хисе туа, үзеңне саклау теләге уяна. Тик еш кына коткыга бирелү өчен объектив сәбәпләр булмый да! Хәзерге мизгел яссылыгында карасак та: әйе, дөньяда нидер бара, вакыйгалар күп. Әмма коткыга бирелерлек сәбәп юк бит әле. Моңа да карамастан, кеше борчыла, эче поша. Ник? Чөнки аңы алга таба нәрсә булачагын һәм бу вакыйгаларның шәхсән ничек тәэсир итәсен күрсәтә. Куркыныч сурәтләр пәйда була, кыскасы. Бу чынбарлыкка туры килгән сурәтләрме, әллә фантазия җимеше генәме – баш миенә барыбер!

Шулай да, минемчә, коткыга бирелү, борчылу, хафалану юк урында барлыкка килми. Аның нигезле аңлатмасы бар. Йә ул кешенең шәхси негатив тәҗрибәсенә бәйле, йә ата-бабаларныкына. Шул ук сугыш чорында кемдер концлагерьларда булган, ачлык, сугыштан соңгы авырлыклар кичергән… Әгәр дә әлеге «тәҗрибә»не оныту өчен берни эшләнмәгән икән, ул буыннан-буынга күчеп киләчәк.

2. Борчылу, курку хисләре аек акылдан өстенрәк чыкса, нишләргә?
Курку хисен сүндереп булмый. Ансыз кешелек дөньясы гомумән хәзерге көнгә килеп җитмәс, яши алмас, үлеп беткән булыр иде. Ул – кирәкле хис. Әмма, иң мөһиме, курку хисе белән кеше үзе идарә итәргә тиеш. Киресенчә түгел! Әгәр дә курку аек акылдан да өстенрәк чыга икән, бу инде белгечләргә күренергә бер сәбәп. Моңа тыныч кына карарга ярамый. Гадәти яшәү рәвешен алып бармастай курку хисе белән алуның сәбәпләре тирәндә ятарга мөмкин.

3. Тотрыксыз вазгыятьтә курку хисен ничек җиңәргә?
Дөнья шулай корылган: ул элек тә, хәзер дә һәм киләчәктә дә куркыныч булачак. Дөньяда хәвеф-хәтәр гел булган һәм булып торачак. Әгәр дә кеше миңа беркайчан да куркыныч янамаячак, барысы да яхшы булачак дип кенә яши икән, бу инде паника, невроз халәтенә туры юл. Дөнья белән идарә итеп булмый. Без тәэсир итә алган һәм итә алмастай очраклар бар. Моны аңларга кирәк. Аңлаган очракта җиңелрәк булачак. Коткы хисеннән котылу өчен әнә шул очракларны таный, аерып карый белергә кирәк. Сәяси карарларга ул тәэсир итә алмый. Мондый вазгыятьтә игътибарны «Мин нәрсә эшли алам?» дигән сорауга юнәлдерергә кирәк. Әйтик, бер-бер хәл булса, үземне һәм якыннарымны ничек кайгыртачакмын, азык-төлек ничек юнәтәчәкмен һәм башкасы. Бу – иң табигый һәм дөрес юл. Иң аянычы – коткыга бирелеп, кешенең начар гадәтләргә алынуы.

4. Ничек тынычланырга?
Сулыш гимнастикасы булыша. Кешене куркыныч уйларыннан йолкып алырга кирәк. Шул ук өй җыештыру, табак-савыт юу, кул белән кер юу да булыша.

Ярдәмләшү, хәйрия эшләре белән мавыгу да уңай тәэсир итә. Әйтик, шул ук авыр хәлдә калганнарга матди ярдәм яисә кирәк-яраклар белән булышу. Шул чагында кайгы килсә, мин ялгызым гына аның белән күзгә-күз калмаячакмын дигән ышану туа. Сугыш чорында күпләр әнә шулай бердәм булганга, ярдәмләшеп яшәгәнгә коткыга бирелмәгән.

Тагын бер нәрсәгә игътибар итми мөмкин түгел. Ул да булса кешенең тирә-юне, мохите. Әгәр дә телефоныгыздагы, социаль челтәрләрдәге хәбәрләр негатив белән тулган икән, бу сезнең организмга начар тәэсир итәчәк. Стресс гормоны – кортизол бүленеп чыгуын арттырачак. Кем белән нинди темага сөйләшүегезгә игътибар итегез. Әңгәмәдәшегез һөҗүм итүләр, куркыныч вакыйгалар хакында гына сөйли икән, моннан файда юк. Бу – аның стресс белән көрәшү алымы. Әмма сезгә моннан җиңелме соң? Гадәттә, юк. Шуңа күрә мондый сөйләшүләрдән ерактарак торырга кирәк. Яисә аның юнәлешен үзгәртергә. Әйтик, сине эвакуацияләнгән кешеләр язмышы борчый икән, кием-салым белән булыш, хәйрия эшендә катнаш. Әгәр дә моңа әзер түгелсең икән, бу хакта сүз куертып торырга да кирәкми. Сезнең рухи халәтегез – сезнең җаваплылыкта, башкаларныкы – үзләрендә. Кешегә җаваплылык хисен кире кайтарырга кирәк. Мин, гомумән, социаль челтәрләрне, хәбәрләр тасмасын чикләргә киңәш итәм. Бик кызыксынганнар моңа аерым бер вакыт бүлеп бирә ала, ә калган вакытны үзләренең көнкүреш эшләрен башкаруга багышласын иде.

Икътисади халәт

Соңгы арадагы вакыйгалар акча тирәсендә дә ыгы-зыгы тудырды. Үзгәрешләр гади халык кесәсенә сугармы? Валютаның уйнавы нәрсәдә чагылачак? Акчаны сакларгамы, кулланыргамы, алмаштырыргамы?

Финанс белгече Ләйсән ХАЛИКОВА белән бергә акча мәсьәләсендәге шау-шуның сәбәпләрен ачыкларга тырыштык.

1. Күпләр 90 нчы еллар кабатланыр, акча калмас, булганы да җилгә очар, дип борчыла. Безне нәрсә көтә?
Бу сорауга җавап бирергә иртәрәк. Коткыга бирелергә кирәк түгел дип уйлыйм. Банкоматларда күпләп чират тора башладылар. Монда инде мәгълүмат тизлеге үз ролен уйнады. Бер кеше нидер эшли икән, икенчесенә дә аның артыннан шуны ук кабатларга кирәк дип уйлыйлар. Доллар сатып алырга, исәп-хисап счетыннан акчаны алырга диләр икән, барысы да банкка йөгерә. Күпчелек артыннан кабатларга түгел, кеше үз башы белән уйларга тиеш.

2. Валютаның уйнавы нинди нәтиҗәгә китерер?
Импорт, экспорт дәвам итә икән, доллар һәм евроның үсүе без сатып алаcы товарларның кыйммәтләнүенә китерәчәк. Доллар үзгәреп тора. Бүген иртән 100 сумга менде, узган кичтә 85 иде. Долларның бәясе очсызланыр дип көтәргә кирәкми. Ул үсүгә таба бара. «Финанс мендәре»н булдырган кешеләргә дә еш кына диверсификация ясарга киңәш итәбез. Ягъни акчаның бер өлешен долларда, бер өлешен сумнарда тотарга. Башка валюталарны да карарга була. Анысын һәр кеше үзе хәл итә.

3. Хәзер валюта сатып алу өчен кулай вакытмы?
Хисләргә бирелергә кирәкми. Инде соңга калдык дип әйтергә дә була. Хәзер шундый «кызу» чакта сатып алырга киңәш итмәс идем, чөнки бәясе бик нык артып китте. Россия икътисады – волатиль, ягъни үзгәрүчән, җиңел идарә ителә торганнардан. Шуңа күрә ашыгыч адымнарга бармаска кирәк.

4. Банкта калган акчаның «янмавына» гарантия биреп буламы?
Безнең кертемнәр иминиятләштерелгән. Әмма, алай дисәк тә, әгәр дә ил авыр хәлдә кала икән, акча җитмәгән очракта, дәүләт аны кешеләрдән дә алып торырга мөмкин. Әмма бу әле дөреслеккә туры килә дигән сүз түгел!

5. Киеренке вазгыятьтә бурычларны реструктурлаштыру, кредитны «кичерү» кебек чараларга өметләнеп буламы?
Бу вазгыятьнең никадәр озак вакыт дәвам итүенә бәйле. Әгәр дә кешенең эше булып торса, аңа хезмәт хакы түләнәчәк дигән сүз. Яшәргә, азык-төлек алырга мөмкинлеге була. Әлегә ниндидер ташламалар турында сүз йөртергә иртәрәк. Бу җәһәттән кешене өметләндерү куркыныч.

Кредитны «кичерү» турында әйткәндә, ниндидер вакытлыча кичектерүләр турында гына хыялланырга мөмкин. Әле ул кадәр киеренке чорга җиттек дип әйтмәс идем.

6. Акчаны сак тоту өчен нишләргә?
Әйткәнемчә, диверсификация ясарга. Акчаны бер валютада гына тотмаска.

7. Кибеткә барып, күпләп товар сатып алып куярга, запас тупларгамы?
Юк! Ризык артыннан чабарга кирәкми. Кешенең коткыга бирелеп, кибет киштәләрен бушата башлавы кытлыкка китерергә мөмкин. Авыр вазгыятьне үзебез тудырмыйк. Кирәк кадәрен генә алыйк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘСТЕРХАНГА ЯРАГАН ТАТАРСТАНГА БАРАМЫ?

Россиядә «Шәхси хуҗалыклар турында»гы федераль законга үзгәрешләр кертелергә мөмкин, чөнки Дәүләт Думасында яңа закон проекты каралачак. Әстерхан өлкәсе Думасы депутатлары тәкъдим иткән проектның асылы шәхси хуҗалыкларда терлек санына квота билгеләүдән гыйбарәт. Ягъни аларның өметләре акланса, шәхси хуҗалыкларда асрарга мөмкин булган терлек санын һәр төбәк үзе билгеләргә тиеш була. Сан артып китсә, хуҗалык башлыгына шәхси эшмәкәр булып теркәлергә туры киләчәк. Ә эшмәкәр булгач, салымын түләячәк дигән сүз. Әстерханга яраган Татарстанга барамы? Закон кабул ителгән очракта, шәхси хуҗалыкларга ни яный? Без әлеге четерекле закон проектын өйрәндек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Баетмас, бөлдерер

Россельхознадзор җитәкчесе Сергей Данкверт та моңа кадәр шәхси хуҗалыкларда тотылучы терлек санына карата үз фикерен белдергән иде. «Монда эш менә нәрсәдә: әгәр закон тарафыннан шәхси хуҗалыкларның нәрсә эшләргә тиешлеге билгеләнмәгән икән, ул, 30 дуңгыз асрап, эшмәкәрлек эшен алып барырга мөмкин. Бу шәхси хуҗалык була аламы? Шуңа күрә чикләрне билгеләргә кирәк», – диде ул.

Бу проблема башка төбәкләрдә очраса да, Татарстанга хас түгел. Бездә мондый хуҗалыклар я фермер, яки шәхси эшмәкәр булып теркәлә. Ләкин федераль закон кабул ителгән очракта, үзгәреш җилләре барлык субъектларга да кагылачак.

Ел башындагы мәгълүматлар буенча, Татарстанда 468 мең шәхси хуҗалык исәпләнә. Алар республикадагы авыл хуҗалыгы продукциясенең 41,4 процентын җитештерә. Бу – 98,2 млрд сум акча дигән сүз. Росстат мәгълүматларыннан күренгәнчә, Татарстанда сыерларның – 42, кәҗә һәм сарыкларның – 46, атларның 49 проценты шәхси хуҗалыкларда асрала. Әлеге закон кабул ителә калса, халык терлек асраудан туктамасмы? Ә бит соңгы биш елда аларның саны болай да артуга таба бармый. Шушы еллар эчендә шәхси хуҗалыклар – 29 процентка, фермерлар дүрттән бер өлешкә, тармактагы эшмәкәрләр 45 процентка кимегән.

Азнакай районының Урманай авылында яшәүче ирле-хатынлы Галия һәм Зирәк Мөхәммәтшиннар менә инде шактый еллар үзләре җитештергән продукцияне сатып көн итә. Ел әйләнәсе атнасына берничә тапкыр район үзәгенә барып, үз хуҗалыкларында җитештергән продукцияне саталар. Моңа кадәр өч сыер сауган булсалар, узган ел икегә генә калдырганнар. Шул өч сыерның сөтен, каймагын, катыгын, ак һәм кызыл эремчеген, кортын, маен ясап сата алар.

– Файдасы бар, әлбәттә. Акчаны җыеп, зур әйберләр алдык, димәсәк тә, алган кредитларны түләп барырга җитәрлек кереп бара. Анысы да зур ярдәм, сөтнең кереме начар түгел. Ләкин чыгымы да күп. Терлек азыгын тулысынча сатып алабыз. Бу закон проекты турында ишетмәгән идек әле. Тагын фермер, эшмәкәр булып теркәләсе булса, авылда беркем дә мал тотып азапланмаячак инде. Күңел төшеп китте, әлбәттә, тик бездә андый дәрәҗәгә барып җитмәсләр дип өметләнәм, – ди хуҗабикә.

Белгечләр фикеренчә, терлек санына чикләүләр кертү һәм эре шәхси хуҗалыкларны шәхси эшмәкәрләр буларак теркәү бюджет казнасын салым белән баетуга әллә ни зур йогынты ясамас. Ә менә хуҗалыкларны бетерергә һәм эшчәнлекләрен «күләгә»дә алып барырга бик яхшы сәбәп булырга мөмкин.

Татарстанның сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе урынбасары Артур Николаев та шул фикерне куәтләде. Алай гына да түгел, ул хәттә шәхси хуҗалыкларны үстерүне социаль проект буларак карарга кирәк дип саный.

– Без халыкны авылда калдыру турында сөйлибез. Ләкин анда эш табу җиңел түгел. Әйе, безнең күпчелек районнарда сәнәгать мәйданнары, үсеш ноктасы бар, тик күпчелек барыбер җирдә эшләргә күнеккән. Шуңа күрә хуҗалык итүнең бу формасы мөһим, – ди ул.

Чикләү түгел, ярдәм кирәк

Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев фикеренчә, әлеге закон проекты Россиянең киң далалы, күп терлек асраучы төбәкләре өчен туры килә.

– Россиянең 85 төбәге бар. Киң далалары булган субъектларда 100әр, хәтта меңәр баш мал тоткан шәхси хуҗалыклар бар, – ди ул. – Безнең аңлауда шәхси хуҗалык үз-үзен тәэмин итәрлек ризык әзерләргә тиеш. Ә бу юл белән алар салымнан качу мөмкинлеген карый дигәнне аңлата. Бу проблема безнең республикага хас түгел. Ләкин шундый хәл булды дип күз алдына китерик әле. Күршегез 50 баш мал тотса, сезгә ошар идеме? Моннан тыш, ветеринария кагыйдәләре дә бар бит әле. Аларны үтәмәгән очракта, авырулар килеп чыгу куркынычы артуын да аңлыйбыз. Татарстандагы шәхси хуҗалыкларга игътибар һәрвакыт зур булды, чөнки барыбыз да авылда сыер булмаса, аның тотрыклылыгы, кереме бетүен аңлыйбыз. Ә мал тоту җиңел түгел, аеруча азык әзерләүдә авырлыклар бар. Язгы җыелышларда да без бу мәсьәләләрне кузгатачакбыз.

Фермер, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе президенты Камияр Байтемиров исә әлеге үзгәрешләрне гомумән бер генә субъектка да кертмәү яклы.

– Бер яктан, авыллар тарала. Икенче яктан, авылдан халык кача, – ди ул. – Татарстанда шәхси хуҗалыкларга каршы килә торган үзгәрешләр булмас дип уйлыйм. Чөнки бездә, киресенчә, аларга ярдәм чаралары уйлап табылды. Һәм бер көнне маллар үрчетергә, тавыклар асрарга тыйсыннармы? Хрущев заманында терлекләрнең баш санын чикләү кертелгән иде. Ләкин бу нәрсәгә китерде? 60 нчы елларда базарда сатар өчен ит бетте. Ипи җитми башлады. Шуңа күрә барысы да бер-берсенә бәйле. Мондый закон чыкмаганда да авылдан 101 мең кеше китте. Безгә әле беренче чиратта халыкны, аның малын саклап калуны кайгыртырга кирәк.

Әлеге закон проектына карата Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан да берәр төрле фикер алырга өметләнгән идек. Тик, кызганыч, әлегә ачык кына җавап бирүче булмады. Шулай да министрлыкның бу закон проектын хупламавы аңлашылды.

Таһир Һадиев әйтүенчә, шәхси хуҗалыклардагы мал санына кагылышлы закон проектының безнең өчен бер уңай пункты бар: шәхси хуҗалык булып калыр өчен баш санын һәр төбәк үзе билгели алачак. Бөтен өмет тә әнә шунда. «Без исә «алтын урталык»ны табачакбыз», – дип ышандырды депутат.

Тавык чалу тыела?

– Мин киләчәктә барыбер шуңа таба барырбыз дип уйлыйм, – диде республикада танылган фермер. Кызганыч, билгеле сәбәпләр аркасында ул исемен күрсәтмәүне үтенде. – Терлек азыгы кыйммәт булу сәбәпле, болай да авылда күпләп мал тота алмаучы халыкны кысрыклау бара. Бу закон – аларга үз продукцияләрен җитештерү өчен тагын бер киртә булачак. 2023 елның 1 гыйнварыннан шәхси хуҗалыклар тавыкларын да сугым пунктларында чалдырырга тиеш булачак. Махсус урыннарда чалынмаган һәм ветеринар тикшерүе узмаган кош-корт итен саткан очракта, хуҗалык башлыгына штраф яный. Менә шулай итеп халык үзе үстергән тавыгын да сата алмас дәрәҗәгә җитәчәк. Һәм киләчәктә кибеткә юл тотачак.

Белгечләр, фермерлар, җитәкчеләр белән әлеге тема турында сөйләшкәндә, шәхси хуҗалыкларда ветеринар кагыйдәләр үтәлмәү, шул исәптән кош-кортлар тоту, чалу мәсьәләләре дә еш телгә алынды. Кайбер район үзәкләрендә кош-корт тоту белән бәйле авырлыклар да килеп туган икән, дигән хәбәр дә килеп ирешә.

– Без Нурлатта үз йортыбыз белән яшибез. Күп итеп тавыклар тота идек. Узган ел ахырында «Водоканал» хезмәткәрләре кош-корт тотучыларга салым түләтерәләр икән, дигәч, тавыкларыбызны авылга кайтарып куйдык. Дөрес, ул сүздән генә дә курыкмадык. Сараебызны яңартырга кирәк иде. Мондый карарга килер өчен шул сәбәп җитә калды. Ләкин бу хәбәрне ишеткән күршеләребез дә тавыкларын эшкәртеп бетерде, – диде Нурлатта яшәүче Рәмзия ханым.

Шөкер, монда ветеринария кагыйдәләренең катышы булмавы ачыкланды. Сүз, исәпләү счетчигы булмаган очракта, су тарифын ишегалдындагы кош-корт, мал санына карап билгеләү турында барырга мөмкин, дип аңладык.

Тик без шулай да үзен күрсәтмәүне сораган фермерның сүзләренә ачыклык кертер өчен, Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Илдар Нугумановка чыктык. «Әйе, чыннан да, киләсе ел башыннан шәхси хуҗалыкларда тавык чалуга бәйле үзгәрешләр керәчәк, – дип раслады ул. – Ләкин бу үзләренә ашар өчен түгел, ә сатуга алып барган очракларда үтәлергә тиешле шарт булачак».

Зөһрә САДЫЙКОВА

Рөстәм ГӘРӘФЕТДИНОВ, эшмәкәр:

Авыл хуҗалыгы – зыянга эшли торган тармак. Шәхси хуҗалыкта эшләп баю мөмкин эш түгел. Авыл хуҗалыгының бизнес түгел, ә яшәү рәвеше икәнлеген аңлау мөһим. Тик булган ярдәм чаралары тармакны үстерергә җитми.

ТҮБӘҢ КИТМӘСЕН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Югары булуы да куркытмый

Апас районында яшәүче Алсу һәм Илнур Садыйковлар да бүген ничек фатир алырга дип баш вата. Яшь гаилә әлегә район үзәгендә фатир арендалап яши. «Мин декрет ялында. Иремнең хезмәт хакы белән банктан 2 миллион сумга кадәр генә кредит рәсмиләштерә алабыз дигән җавап килде. Бу бер бүлмәле фатир алырга да җитми. Үзебез җыйган акча да күп түгел. Шуңа якындагы берәр авылдан искерәк кенә булса да йорт алып торыйкмы дип тә уйлый башладык. Акрынлап, яңартып чыгар идек әле», – ди Алсу.

Казанның «Кояшлы шәһәр» микрорайонында яшәүче Равил Галиев исә хәзер яшәгән бер бүлмәле фатирын сатып, ике бүлмәлесен алырга хыяллана. «36 квадрат метрлы бер бүлмәле фатирда дүрт кеше яшибез. Үзебезнең тирәдәге ике бүлмәле фатирлар бик кыйммәт – 7 миллион сумга якын. Андыйны алырга көчебез җитмәячәк. Шәһәр яныннан йорт алыгыз, диләр. Әче таңнан торып, көн саен сәгатьләр буе «бөке»дә утырып эшкә, укырга бару куркыта», – ди ул.

Бер ел эчендә Казанда яңа төзелеп килүче йортлардагы фатирлар 38 процентка кыйммәтләнгән. Искерәк фатир бәяләре исә 28,3 процентка арткан. Озак еллар бу тармакта хезмәт куйган риелтор Дамир Сафиуллин сүзләренә караганда, бер ел эчендә башкалада фатирларга ихтыяҗ 52 процентка арткан. «Соңгы арада фатир бәяләренең котырып өскә үрмәләвенә китергән иң төп сәбәпләрнең берсе әнә шул. Акча очсызлана. Шуңа күрә кеше акчасын кая да булса урнаштырып калырга тырыша. Аларны хәтта ипотека ставкаларының югары булуы да туктатмый», – ди Дамир.

Белгеч фатир бәяләре артуга китергән тагын берничә сәбәпне атый. Хәтерләсәгез, узган елның октябрендә Үзәк банк алтынчы тапкыр төп ставканы 0,75 процентка (6,75 проценттан 7,5 процентка кадәр) күтәрде. Белгечләр шушы яңалыкка бәйле рәвештә Россиядә барлык кредит төрләре дә кыйммәтләнәчәк, ипотека ставкалары артачак, милеккә сорау кимү аркасында, милек базары туктап калачак дип фаразлады.

– Фатир бәяләре артуга төзелеш материаллары кыйммәтләнү дә зур йогынты ясады. Төзелештә эшче куллар җитмәүнең дә тәэсире зур. Пандемия аркасында Татарстанга читтән килеп эшләүчеләр дә кимеде. Шул сәбәпле күп кенә оешмалар йорт төзү вакытын озайтырга мәҗбүр, – ди Дамир Сафиуллин.

Якыны кыйммәтрәк

Узган ел Татарстанда 342 миллион сумлык 60,5 мең ипотека кредиты бирелгән. Татарстан буенча Росреестр идарәсе башлыгы урынбасары Лилия Борһанова сүзләренә караганда, фатирларның бик нык кыйммәтләнүе аркасында соңгы арада республикада үз йорты белән яшәүне өстенрәк күрүчеләр саны арткан. Гыйнвар аенда гына да республикада йорт алырга дип 700 килешү рәсмиләштерелгән. Узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 37 процентка күбрәк бу. Ел башыннан бирле җир участогы алу өчен 2,4 мең ипотека килешүе рәсмиләштерелгән. Фатир алу өчен исә 3,7 мең кредит бирелгән. Бу узган елның гыйнвары белән чагыштырганда 17 процентка күбрәк.

Бүген Казанда фатирларның бер квадрат метр бәясе уртача 114 мең сум тирәсендә тирбәлә. Иң кыйммәтлеләрнең берсе саналган Совет районында төзелеп бетмәгән йорттагы бер бүлмәле фатирның квадрат метры 157 мең (!) сумга кадәр җитә. Гомумән алганда, Казанда бер бүлмәле фатирның бер квадрат метры – 130–200 мең сум, ике бүлмәленеке – 100–170 мең сум, өч бүлмәленеке 90–150 мең сум тирәсендә тирбәлә. Шул рәвешле башкалада бер бүлмәле фатир – уртача 4,5 миллион сумга, ике бүлмәлесе – 6 миллион, өч бүлмәле фатир 7 миллион сумга төшә.

Дөрес, мондый фатирларны элеккеге «хрущевка»ларда яки шәһәр читендә төзелеп килүче яңа йортларда гына табарга мөмкин. Үзәккә якынлашкан саен, фатир бәяләреннән чәчләр үрә тора. Фатир хакына, аның кайда урнашуыннан тыш, җәмәгать транспорты, метроның булу-булмавы, инфраструктура, мәктәп, балалар бакчасының янәшә урнашуы, якын-тирәдә кибет, даруханәләрнең булуы да йогынты ясый. Башкаладагы иң арзанлы фатирлар – Авиатөзелеш һәм Киров районнарында, иң кыйммәтләре Вахитов, Совет һәм Яңа Савин районнарында урнашкан.

Процентлар үсәчәк

Дамир Сафиуллин сүзләренә караганда, бүген Казанда студия белән бер бүлмәле фатирларга ихтыяҗ зур. Аларны сатып алырга мөмкинлеге булмаган кеше тулай торактан бүлмә йә гостинка алырга тырыша. «Әгәр кеше хәзерге фатирын сатып, зуррагын алырга планлаштырган булса, хәзер моны эшләү өчен иң кулай вакыт. Әгәр кеше әле беренче тапкыр гына торак алырга җыена икән, әлегә беразсабыр итеп торырга кирәк. Ник дигәндә, хәзер иске «хрущевка»ларда бер бүлмәле фатирны да 4 миллион сумнан да арзангарак алып булмый. Бу фатирны ипотекага рәсмиләштергән очракта, аның өчен ай саен уртача 36–38 мең сум акча түләп барырга туры киләчәк. Татарстандагы 30–33 мең сумлык уртача хезмәт хакы белән күпләр бу чыгымнарны тарта алмый», – ди риелтор.

Айлык түләү димәктән, Дамир Сафиуллин, әр-яңа йорттан фатир алырга теләгән, кулында беренче кертем өчен 1,5–2 миллион сум чамасы акчасы булган кешегә төзүчедән субсидияләнгән ставка алырга киңәш итә. Бу ни дигән сүз? Әйтик, кайбер төзүчеләр, «Гаилә ипотекасы» программасы буенча бирелгән 5 процентлы кредитка ташлама ясый. «Дөрес, ул ташламалы процентны өстәмә акча түләп сатып алырга туры киләчәк. Әмма бу – үз-үзен аклый торган гамәл. Ник дигәндә, шул рәвешле сезнең айлык түләвегез шактый кимеячәк. Мисал өчен, «Гаилә ипотекасы» программасы буенча аена 6 миллион сум кредит рәсмиләштерсәң, ай саен 39 мең сум акча түләп барырга туры киләчәк. Ташламалы ставка сатып алып, ипотека ставкасын 0,1 процентка киметсәң, кредит буенча айлык түләү уртача 20 мең сумга кадәр кимеячәк. Әмма шунысы бар: ставкасы әлеге ысул ярдәмендә киметелгән ипотека кредитын киләчәктә рефинанслап булмаячак», – ди риелтор.

«Авито» порталы белгечләре уздырган тикшеренү нәтиҗәләренә ышансаң, Татарстанда уртача хезмәт хакының өчтән бер өлешен фатир алырга дип җыеп барсаң, моның өчен 33–36 ел вакыт кирәк булачак икән. Хезмәт хакының яртысын янда калдырып барсаң, якынча 20–22 елдан үз куышыңны булдырырга мөмкин, дип ышандыра белгечләр.

– Торак бәяләре тотрыклыланыр ул. Болай кисәк кыйммәтләнгәннән соң, гадәттә, торак бәяләре берaз үзгәрешсез торып ала. Ләкин моның кайчан булачагын әлегә фаразлавы кыен. Ипотека процентлары исә алга таба да үсәчәк кенә. Моңа бу көннәрдәге вакыйгалар да йогынты ясаячак. Доллар курсы үсәчәк. Аны тоткарлау өчен Үзәк банк ставканы арттырачак, – дип фаразлый Дамир Сафиуллин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАЗАНДА БЫЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫНА ФАТИР БӘЯЛӘРЕ

(Domofond.ru мәгълүматлары)

Район	Яңа төзелгән йорттагы фатирның квадрат метр хакы	Икенчел торак базарындагы фатирның квадрат метр хакы
Авиатөзелеш	114,2	116,6
Вахитов	204,9	154,4
Киров	109,3	109,1
Мәскәү	мәгълүмат юк	111,4
Яңа Савин	167,3	140
Идел буе	114,9	123
Совет	137,3	128

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фатир сатып алырга җыенучыларга киңәшләр

➤Фатир алу уен эш түгел. Шуңа күрә торак базарындагы үзгәрешләрне, фатир бәяләрен даими күзәтеп барыгыз. Яңа гына фатир сатып алган кешеләр белән аралашып тору да комачауламас.

➤Булачак фатирыгыз эш урыныгыздан ерак урнашмаса, яхшырак. Эштән өеңә бер сәгать кайтасың икән, ул көнөнә ике сәгатьлек юл дигән сүз.

➤Фатир алганда тәҗрибәле риелторга мөрәҗәгать итегез. Ул сезгә күңелегезгә якын фатир гына табып калмыйча, аны дөрес итеп рәсмиләштерергә дә ярдәм итәчәк. Бик күп хата һәм югалтулардан да саклап калачак.

➤Икенчел торактан фатир алырга теләүчеләргә иң элек хуҗаларның түләнмәгән кредитлары юкмы икәнлеген ачыкларга кирәк. Юкса төп башына утыртулары ихтимал.

➤Беренчел кертемгә акчаны каян табарга белмәүчеләргә акчаны картада түгел, кәгазь рәвешендә тотарга кирәк. Ник дигәндә, банк картасында чакта акча су урынына ага. Аның кая киткәнен дә чамалап бетереп булмый. Кулыңда тотканда акчаның исә кадере арта, аны юк-барга тотасы килми.

28 февраль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00, 02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «КОНЬКИ ДЛЯ ЧЕМПИОНКИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Черное озеро» 16+
00.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ЯНЫЧАР». Многосерийный фильм (S) 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
01.05, 03.05 «Время покажет» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «ЗАЦЕПКА» 16+
17.30 Премьера. «Малахов» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЛИНИЯ СВЕТА» 12+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.15, 14.35 Новости
06.05, 22.10, 01.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 04.55 Спецрепортаж 12+
09.25 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор 0+
10.20, 04.00 Зимние виды спорта. Обзор 0+
11.15 «Есть тема!» Прямой эфир.
12.20, 14.40 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ» 16+
16.55 «Громко». Прямой эфир
17.40 Регби на снегу. Чемпионат Европы. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Москвы.
18.30 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Рубин» (Казань). Прямая трансляция
21.00 После футбола с Георгием Черданцевым
22.00, 02.55 Новости 0+
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Аталанта» – «Сампдория». Прямая трансляция.
00.45 Тотальный футбол 12+
01.45 Лыжный спорт. Фристайл. Ски-кросс. Кубок мира. Трансляция из Миасса 0+
03.00 «Несерьёзно о футболе». Док. фильм 12+

НТВ

04.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.20 «ЧЕЛОВЕК НИОТКУДА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «СЕЗОН ДОЖДЕЙ» 16+
07.00 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Поскребыш» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «БЕЛОЕ ПЛАТЬЕ» 16+
16.55 «КАРУСЕЛЬ» 16+
19.00 «СЛЕДУЯ ЗА СЕРДЦЕМ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.55 «Порча» 16+
02.25 «Знахарка» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «КУРЬЕРСКИЙ ОСОБОЙ ВАЖНОСТИ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.20, 18.30 «Специальный репортаж». 16+
09.40, 02.25 «НЕИСПРАВИМЫЙ ЛГУН» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Сделано в СССР» 12+
13.45, 14.05 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
14.00 Военные новости. 16+
18.50 «Непокорённые» 16+
19.40 «Скрытые угрозы». «Альманах №93» 16+
20.25 «Загадки века». Док. сериал 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ» 12+
03.40 «Оружие Победы» 12+

1 март | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00, 02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «КОНЬКИ ДЛЯ ЧЕМПИОНКИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Рустам Минниханов. Жизнь как инновация». Док. фильм 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». «Просвещения век» 12+
00.40 «Вехи истории». Новый век Татарстана 12+
01.05 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
13.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20 «Рустам Минниханов. Жизнь как инновация». Телефильм 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 «ВЛАД ЛИСТЬЕВ. «ЗАЧЕМ Я СДЕЛАЛ ЭТОТ ШАГ?» 16+
01.20, 03.05 «Время покажет» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «ЗАЦЕПКА» 16+
17.30 Премьера. «Малахов» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЛИНИЯ СВЕТА» 12+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.45, 12.15, 14.35, 22.00 Новости
06.05, 19.20, 22.05, 01.15 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 «БЕЗЖАЛОСТНЫЙ» 16+
11.15 «Есть тема!» Прямой эфир
12.20, 14.40 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ». Телевизионный сериал 16+
16.55 Хоккей. КХЛ. 1/4 финала конференции «Восток». «Металлург» (Магнитогорск) – «Барыс» (Нур-Султан). Прямая трансляция
19.55 Футбол. Бетсити Кубок России. 1/8 финала. «Динамо» (Москва) – «Нижний Новгород». Прямая трансляция
22.50 Биатлон. Чемпионат мира среди юниоров. Эстафета. Мужчины. Трансляция из США 0+
23.50 Биатлон. Чемпионат мира среди юниоров. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из США
01.45 Гандбол. Лига Европы. Мужчины. «Нант» (Франция) – «Чеховские Медведи» (Россия) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «Несерьёзно о футболе» 12+

НТВ

04.50 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00 Сегодня
08.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
10.00 Сегодня.
10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.00 Сегодня
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.00 Сегодня
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.00 Сегодня
20.00 Остросюжетный сериал «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
23.20 Сегодня
23.40 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
03.30 Остросюжетный сериал «ЧЕЛОВЕК НИОТКУДА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Младшая сестра» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «МИЛЛИОНЕР» 16+
17.05 «УСЛЫШЬ МОЁ СЕРДЦЕ» 16+
19.00 «КРЫЛЬЯ БАБОЧКИ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
02.00 «Порча» 16+
02.25 «Знахарка» 16+
02.50 «Верну любимого» 16+
03.15 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «ОТЧИЙ ДОМ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Сделано в СССР» 12+
13.45, 14.05 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Непокорённые» 16+
19.40 «Легенды армии». Ф. Голиков 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». Телесериал (к/ст. им. А. Довженко, 1977). 3-я и 4-я серии 12+
02.45 «Нормандия-Неман. В небесах мы летали одних…» Док. фильм 12+
03.40 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.50 «ВЫСШИЙ ПИЛОТАЖ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 28 ФЕВРАЛЬ – 6 МАРТ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Акчалы чор. Бу хәл үзегезне бик юмарт һәм бәхетле кешегә әйләндерер. Язның беренче көннәре сөйкемлелегезне арттырыр. Нәкъ менә шул сәбәпле киркәле кешеләр белән сөйләшү дә уңай нәтиҗәле килеп чыгар.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Тормышыгызны яхшыга таба үзгәртү өчен мөмкинлекләр бер-бер артлы чыга башлар. Бу үзегезне үсендереп җибәрер һәм бик өметле планнар белән яши башлауга китерер. Эштә дә – барысы да тел-теш тидергесез!

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Сөенече дә, бераз гына көенече дә булыр. Көенеч дигәннән, баш бетәрлек хәлләр котелми анысы. Эштәге бераз «кытыршылык» кына… Барысы да шул көнчелек аркасында инде…

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Язның беренче ае матди хәлегез яхшыру белән башланып китәр. Туганнарыгыз да күңелле хәбәрләр белән сөендерер. Ә инде ял көннәренә таба күңел кылларын тибрәтеп җибәрердәй хәлләр булып алыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Эш урынында үз көчегезгә ышанычны бермә-бер арттырып җибәрердәй бер вакыйга килеп чыгар. Яңа танышларыгыз барлыкка килер. Алар үзегезне яңа офыкка чыгарырдай мөмкинлекләр тәкъдим итәр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Хезмәт карьерасында югарырак баскычка үрмәләү өчен әйбәт кенә юл ачылырга тора. Тыйнаклыкны беразга онытып, кыю төстә форсаттан файдаланып калыгыз. Курыкмагыз, булдырачаксыз!

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Торак мәсьәләсен хәл итү өчен бик шәп мөмкинлекләр ачылачак. Җитмәгән акчасы да табылачак, башкасы да булачак! Атна уртасында ирештерелгән бер хәбәр үзегезне уйга салачак. Юк-юк, сезгә аннан начар булмаячак. Киресенчә, бер мәсьәләнең чишелеше генә табылачак.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Атнаның беренче яртысы алга бару өчен әр-яңа мөмкинлекләр барлыкка китерәчәк. Җитәкчегез тырышлыгызны күреп, премия белән сөендерәчәк. Атна ахырында дусларыгыздан матур хәбәрләр ишетеләчәк.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Бу атнада гүя бер горур кыяга әйләнеп калырсыз: башыгыздагы тәп-төгәл планнарны берәү дә җимерә алмаячак! Тырышлыгыз һәм уҗәтлегегез нәтиҗәсендә искитмәле уңышларга ирешәчәксез! .

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Сезнең өчен уңайлы көннәр. Шулай булуга карамастан, шәхси тормышта берникадәр дулкынлану-борчылу булып алырга мөмкин. Көнчелек аркасында шулай.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Акча мәсьәләсендә моңарчы күрелмәгән уңышлар көтегез. Сәбәбеме? Тырышлык һәм бик нык уңай килү. Шуның нәтиҗәсе буларакмы, гаиләгездә искитмәле җылы мөнәсәбәтләр урнашачак.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Тиктормас һәм дә хәйләкәр булуыгыз эшегездә әйбәт кенә уңышка китерәчәк. Әлбәттә, бу матди хәлегезне яхшыртуга да йогынты ясаячак. Атна уртасында бер танышыгыз сәеррәк яңалыклары белән үзегезне тәмам гаҗәпкә салачак.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Сарман муниципаль районы советы һәм башкарма комитеты, әтисе

ИСЛАМОВ Зәкиян Ислам улы

вафат булу сәбәпле, «Татэлектромаш» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Исламов Илдус Зәкиян улының һәм «Агромастер» җитештерү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры Исламов Илгиз Зәкиян улының авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

ХӘРӘКӘТ – ТРОМБ ДОШМАНЫ

pixabay.com

Мизгел эчендәге әҗәл. Бер мизгелдә кеше гомерен өзүче тромбны икенче төрле әнә шулай дип йөртәләр. Соңгы арада тромб, тромб өзелү ише сүзләрне аеруча еш ишетергә туры килә. Моңа әлеге дә баягы коронавирус сәбәпче. Ни өчен коронавирус белән авырып терелүчеләр арасында тромб ешрак очрый? Аны кисәтеп буламы?

Терапевт-кардиолог, медицина фәннәре кандидаты, доцент Ленар КАШАПОВ тромбка бәйле төп сорауларга җавап бирде.

Нидән гыйбарәт? Тромб – гади генә әйткәндә, кан оешу, бик күп күләмдә тромбоцитлар туплану. Аның билгеләре тромбның кайсы урында пәйда булуына бәйле. Әгәр ул аяктагы вена, артерияләрдә барлыкка килсә, кешенең аягы сызлый, авырта, шешә, кызара. Әгәр ул йөрәктәге кан тамырларында барлыкка килсә, кешенең әнә шушы мөһим әгъзасы, күкрәк читлеге борчый башлый. Әгәр тромб баш миенең кан тамырларында хасил булса, инсульт килеп чыгу куркынычы арта. Үпкәләрдә тромб барлыкка килгән очракта кешенең тыны кысыла.

Коронавируска ничек бәйле? Коронавирус тромб килеп чыгу куркынычын арттыра. Коронавирус инфекциясе вакытында кан куеру нәтиҗәсендә үпкәдә микротромбоз барлыкка килергә мөмкин. Ковидтан соң тромб барлыкка килүне кисәтү өчен, кан сыеклагыч дарулар эчәргә киңәш ителә. Әмма аларны табиб белән киңәшкәч кенә кулланырга ярый. Аларны үзлегеннән генә файдалану куркыныч. Әлеге даруларны үз белдегең белән генә кулланса, кан китәргә мөмкин.

> **Абау!**
>
>
>
> Маргарин, бәрәңге һәм банан тромб барлыкка китерергә мөмкин! Америка галимнәре шундый фикергә килгән. «Маргарин составында организм өчен зарарлы трансмайлар күп. Ул майлылыгы бик югары булган ризык санала. Шуңа маргарин йөрәк-кан тамырлары системасына тискәре йогынты ясый. Бәрәңгедә исә крахмал күп. Ул йөрәк-кан тамырлары системасын какшата. Бананны да чама белән ашарга кирәк. Анда витаминнар башка җиләк-җимешләргә караганда азрак. Банан канны куерта. Димәк, тромб килеп чыгу куркынычын арттыра.

Ни сәбәпле пәйда була? Тромб, нигездә, өч төп сәбәп аркасында пәйда була. Иң беренче һәм иң төп сәбәп – кан куеру. Кан тамырлары ялкынсыну, зарарлану да тромб барлыкка китерә ала. Кан әйләнеше бозылу да – төп сәбәпләрнең берсе.

Тромб ни өчен өзелә? Тромб өзелә дә ала, өзелмәскә дә мөмкин. Әгәр тромб кечкенә булса, ул кан тамырының бер өлешен генә зарарлый да, кеше аны сизмичә дә калырга мөмкин. Кан тамырын зур тромб томаласа, кешенең гомере дә өзелергә мөмкин.

Ничек сакланырга? Кан авырулары булган, канны куерудан интеккән кешегә вакытында чарасын күреп, дәваланып торырга кирәк. Тромбны кисәтү өчен һәрчак хәрәкәттә булу да зарур. Болай эшләгәндә кан әйләнеше дә яхшыра, кан тамырлары тыгылу ихтималы да кими. Моннан тыш канны, андагы холестерин күләмен дә даими тикшертеп торырга кирәк. Холестеринны киметмәсәң, тора-бара ул да кан тамырларында тромб кебек оешачак. Чиста су эчү дә файдалы.

Тромб варикоз аркасында пәйда була аламы? Әйе, вакытында дәваламасаң, варикоз да тромбка әверелергә мөмкин. Билгеле булганча, варикоз кан тамырлары киңәю, ялкынсынудан гыйбарәт. Тиз арада чарасын күрмәсәң, тромб барлыкка килүен көт тә тор.

Ишеттегезме?

Каһвә урынына – яшел чәй

Коронавирусның «омикрон» штаммы белән авырып терелгән кешегә каһвәдән баш тарту хәерле. Табиб-невролог Игорь Мацокин сүзләренә караганда, әлеге эчемлек составындагы кофеин организмдагы аденозинтрифосфор (АТФ) кислотасы күләмен киметә. Ул исә энергия белән тәэмин итә. «Моннан тыш кофеин организмнан суны кууы белән дә куркыныч. Димәк, канның куеруына китерә. Каһвә калийны да куа. Шул рәвешле кешенең йөрәк-кан тамырлары системасына да зыян килә», – дип сөйләгән табиб «Новая газета» басмасына. Белгеч «омикрон»нан соң тернәкләнеп килгән кешегә каһвә урынына яшел чәй эчәргә киңәш итә.

Парацетамол үлемгә китерә?!

Шотландиянең Эдинбург университеты галимнәре парацетамолның үлемгә китерә алырдай куркынычын ачыклаган. Бу даруны озак вакыт дәвамында кабул иткәндә, югары кан басымлы кешеләрдә йөрәк авырулары барлыкка килү һәм инсульт булу ихтималы арта. Тәҗрибәдә гипертониядән интеккән 110 кеше катнашкан. 2 атна дәвамында аларның бер өлеше парацетамол кабул иткән, икенче өлеше – плацебо (дару препаратларын тикшергәндә кулланылучы дәвалау сыйфатлары булмаган матдә) эчкән. «Парацетамолны даими кулланганда йөрәк авырулары һәм инсульт куркынычы якынча 20 процентка арта», – дип нәтиҗә ясаган белгечләр. Тәҗрибәдә катнашучылар бу препаратны кабул итүдән туктагач, аларның кан басымы тикшерену башындагы күрсәткечкә әйләнеп кайткан.

Баш авыртып азапласа...



Баш авыртуны гади генә ысуллар ярдәмендә дә җиңәргә мөмкин.

✷Арып, баш авыртса, бер стакан су эчеп куярга кирәк. Андый чакта җылы ванна да булыша.
✷Кара карлыган согы хәтта бик көчле баш авыртуларны да юкка чыгара ала.
✷Башка җиңелчә массаж ясауның да файдасы зур. Мисал өчен: чигә тирәсендәге чәчләрне тарткалап массаж ясарга мөмкин.
✷Баш өянәге вакытында баллы кайнар чәй файдалы.
✷Башны сөлге белән кысып бәйләү авыртуны җиңеләйтә.
✷Кәбестә яфрагы теләсә нинди баш авыртудан булыша. Яфракларны бераз угалап (кайнар су белән йомшартып җибәрергә дә мөмкин) авырткан җиргә куеп торырга кирәк.
✷Кабыгы белән киселгән лимон телемен авырткан чигәләргә ышкуның да файдасы бар.
✷Башыгыз стресстан авыртса, ятып торыгыз, тынычланыгыз.
✷Баш авырту күзгә туры килмәгән күзлек киюдән дә булырга мөмкин. Мондый очракта күзлекне алыштырырга кирәк.

Файдалы рецептлар

ЮТӘЛДӘН ДАРУ

Иң элек 1 стакан кайнаган сөткә 1 аш кашыгы атланмай һәм 1 аш кашыгы бал салырга кирәк. Йомырка сарысына бал кашыгының очына гына чәй содасы салып, аерым савытта яхшылап болгатыгыз. Шул ике катнашманы бергә кушкач, тәмле ризык килеп чыкмас, әлбәттә, тик файдалылыгы буенча тиңнәр булмас. Өч көн дигәндә ютәл сизелерлек кимер.

КАН БАСЫМЫ УЙНАП ИНТЕКТЕРСӘ...

1:1:1 исәбендә кара миләш, балан, бал кирәк. Барысын бергә кушып, пыяла банкага салып, капрон капкач каплап, суыткычка алып куегыз. Әгәр кан басымыгыз күтәрелә башлый икән, шушы катнашманы 1 аш кашыгы алып кабыгыз да 1 стакан җылы су белән эчегез. Балан һәм кара миләш баш авыртуыннан да файдалы. Ә бал исә тынычландыру үзлегенә ия.

ЙӨРӘК ЯХШЫ ЭШЛӘСЕН, ДИСӘҢ...

Йөрәк эшчәнлеген, кан басымын җайга салу өчен бик гади күнегү бар. Моның өчен кулларны салындырып, туры итеп басарга кирәк. Ир-ат – сул, хатын-кызлар уң кулдан башларга тиеш. Бармакларны турайтырга һәм йомарларга. 30–45 секунд эшләргә, 10 секунд ял итәргә һәм шуны ук икенче кул белән кабатларга кирәк. Кулларны ике якка, идәнгә параллель итеп җәяргә, шулай ук кабатларга. Кулларны өскә күтәреп, аннан алга таба куеп, тагын бер кат шулай эшләргә. Күнегүне ашыкмыйча ясарга кирәк. Ул йөрәк-кан тамырлары эшчәнлеген яхшырта, шулай ук гастрит, остеопороздан да файдалы.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТӘРӘЗӘ ТӨБЕНДӘ – ВИТАМИН

Соңгы вакытта сәламәт яшәү рәвешенә өстенлек бирүчеләр арасында тәрәзә төбендә яшел тәмләткечләр («микрозелень») үстерү бик популярлашып китте. Әлеге «модалы» тенденция яшелчә культураларының, кыяклы һәм күп төрле яшел тәмләткечләрнең яшь үсентеләрен кулланудан гыйбарәт. Өендә төрле яшел тәмләткечләр үстерүче Гөлфия Вәгыйзова укучыларыбызга киңәшләрен бирде.

Файдалымы?

Тәрәзә төбендә үстерелә торган яшел тәмләткечләр витаминнар һәм минералларга бай, иммунитетны ныгыта, йөрәк, нерв системасы авыруларын профилактикалау өчен яхшы, организмнан токсиннар чыгара, симерүдән саклый һәм тире һәм чәчләрне матурлый.

Кайдан алырга?

Тәрәзә төбендә үстерелә торган яшел тәмләткечләрне кибеттән сатып алырга, интернеттан заказ биреп кайтартырга һәм үзең өйдә үстерергә дә мөмкин. Аны үстерү өчен әллә ни күп көч тә таләп ителми. Бакчалары булмаган кешеләр өчен дә кулай. Моның өчен ният, бераз тырышлык һәм тәрәзә төбендә яки балконда урын гына кирәк.

Өйдә яшел тәмләткечләрне үстерүнең бер кыенлыгы да юк. Иң мөһим шарт – утырту өчен сыйфатлы орлык сайлау. Әгәр сезнең ел саен чөгендер, редис, кәбестә, салат үстерә торган бакчагыз булса, сез инде орлыклар белән тәэмин ителгән дигән сүз. Ә иң мөһиме, сез аларның экологик яктан чиста булуын һәм бернинди химик йогынтыга дучар ителмәвен төгәл беләсез. Әгәр дә үз бакчагыз юк икән, орлыкны кибеттән сатып алырга мөмкин. Анда пестицидлар юкмы, агулы матдәләр белән эшкәртелмәгәнме – шуңа игътибар итегез. Кибетләрдә аерым орлыкларны да, үстерү өчен кирәкле җыелмаларны да сатып алырга мөмкин.

Ничек үстерергә?

Файдалы яшеллекне өйдә тәрәзә төбендә яки балконда үстерергә була. Аны утыртуның берничә төре бар. Хәзер гадәти яшел тәмләткечләр урынына көнбагыш, борчак, руккола, горчиц, торма, кресс-салат, суган үсентеләрен яратып куллanучылар арта.

Грунтта үстерү. Әлеге гади ысул – иң популяры. Сезгә бары утырту өчен савыт һәм туфрак кына кирәк булачак. Орлыкларны кичтән бүрттерергә куйсагыз, тагын да яхшы. Аннары аларны чәчеп, бераз туфрак белән капларга кирәк. Туфракка су сибеп, савытны пыяла яки пленка белән каплап, якты урынга куярга киңәш итәлә. Орлык тишелеп, беренче яфраклары барлыкка килгәч, савытның өстендәге пыяла яки пленканы алырга кирәк. Суны күп итми генә көненә 1–2 тапкыр сибәргә. Яшел тәмләткечләр утыртканда декоратив үсемлекләр өчен булган туфрак кулланырга киңәш ителми. Чөнки аның составында химик кушылмалар бар, ул тәмләткечнең сыйфатына тәэсир итәчәк.

Мамыкта үстерү. Моның өчен тирән булмаган савытка мамык яки мамык дисклары түшәлә. Орлыкларны 5–10 минут суда тотканнан соң, яхшы итеп дымландырылган мамык өстенә тезеп, пыяла яки пленка белән капларга. Беренче яфраклар күренгәнче каплап тотарга һәм туфракта үстергән төсле үк тәрбияләргә кирәк.

Банкада үстерү. Орлыкларны банкага салалар һәм аз гына су өстиләр. Банка авызын марля белән каплап, резинка белән кыстырып куялар. Беренче шытымнар чыкканчы тәрәзә төбендә тотарга киңәш итәлә. Орлык бераз «үскәч», суын агызып, аны яхшылап юарга кирәк. Аннары аларны сусыз банкага салып, 30 градусы почмак ясап бастырып куярга киңәш итәлә. Бу ысул катлаулырак санала, чөнки банканың эче лайлалана, яшел тәмләткечләрне көн саен чайкарга кирәк.

pixabay.com

Исеңдә тот!

- Яшел тәмләткечне теләсә нинди савытта, тәрәзә төбендә дә үстереп була.
- Үстерү өчен махсус җиһазлар, лампалар, өстәмә җылылык чыганаклары да кирәк түгел.
- Яшел тәмләткечкә корткычлар һәм авырулар зыян салыр дип куркасы юк. Чөнки әлеге үсентеләр 7–13 көн эчендә өлгерәләр. Шунлыктан ашламаларга һәм саклау чараларына өстәмә чыгымнар таләп ителми.
- Суны аз-азлап, пульверизатордан көнгә 1–2 тапкыр сиптерү дә җитә.

Белеп тор!

- Яшел тәмләткечләр бигрәк тә өлкән яшьтәге кешеләр өчен файдалы. Чөнки яшь барган саен, организмда токсиннар күбрәк җыела. Ул алардан котылырга ярдәм итә. Ә балаларга 7 яшьтән соң яшел тәмләткечләр кулланырга ярый.
- Укроп – ир-ат, ә петрушка хатын-кызлар тәмләткече дип санала.
- Рәйхан (базилик) табигый антидепрессант булып санала һәм аны яшелчә белән генә түгел, җиләк-җимеш белән дә кулланырга мөмкин.
- Руккола үсентесен даими куллану организмны яшәртә, сәламәтләндерә.

Лалә кышын да үсә

Минзәлә районында яшәүче Гөлсем Шәрифҗанованың тәрәзә төбен тутырып, лаләләр чәчәк атып утыра. «Мондый матурлыкны тудыруның бер кыенлыгы да юк», – ди ул.

– Көз көне үк, тартмага балчык салып, суганнарны шунда утыртам. Тартманы, суганнар өшемәслек итеп, кышка бакчада тирән чокырга күмеп куям. Гыйнварның егермеләрендә тартманы казып алып, өйгә алып керәм дә тәрәзә төбенә куям. Аны гадәти чәчәкләр, гөлләр караган кебек тәрбиялим. Февральдә минә шулай матур итеп чәчәк аталар, – дип сөйләгән ул «Минзәлә-информ» басмасына.

ТЫРНАКЛАРЫҢ БИГРӘК МАТУР

Әгәр быел яз модадан калышмыйм дисәгез, тырнакларыгызны акка буягыз.

Ак төстәге маникюр төрле яшьтәге хатын-кызларга да килешә, бары үзегезгә ошаганын сайлап алырга гына кирәк. Монда сүз ап-ак лакка буяу турында гына бармый.

Кемгәдер аклы френч, кемгәдер классик ак, «нюд»тан алып, сөт төсенә якынрак төстәге маникюр туры килер. Акка төрле төстәге бизәкләр дә артык булмас, кыскасы, фантазиягезне эшкә җигегез дә үзегезгә ошаганын сайлагыз.

Әмма тырнакларны буядым да эш бетте, дияргә ярамый. Аны хәстәрләү турында түбәндәгеләрне белеп тору да комачауламас.

Спа-маникюр. Бу процедура тырнакларны сәламәтләндерү өчен кирәк. Дөрес, ул вакыт сорый, тик нәтиҗәсе сезне шатландырмый калмас. Кулларга шулай ук ванна, пилинг, массаж ясарга, крем сөртергә кирәк. Зәйтүн, әрекмән мае тырнакны витаминнар, минераллар белән тукландыра. Желатин аксым белән баетачак, тырнакның сыгылмалылыгын кайтара. Лимон согы сары тапларны бетерә, тырнакны тизрәк үстерә.

Крем. Тырнаклар сәламәт булсын өчен, салкында туклындыргыч крем сөртергә һәм бияләй яки пирчәткә киярг иренмәгез. Ә җәен дымландыргыч крем сөртегез. Тырнакларыгыз һәрчак матур булсын дисәгез, тау кадәр савыт-саба юганда резин пирчәткә киярга гадәтләнегез.

Минераллар. Тырнак сәламәт булсын өчен, цинк, кремний, тимер, магний, селен, күкерт, кальций кирәк. Юка, сынарга гына торган тырнаклар тимер җитмәүне аңлата, күкерт җитмәгән очракта тырнакның пластинасы бозыла.

Туклану. Тырнакларның матурлыгы туклануга да бәйле. Балык, йомырка, яшел тәмләткечләр, кузаклы, бөртекле культуралар, чикләвек, көнбагыш, болгар борычы, шпинат, помидор ашау яхшы нәтиҗә бирер.

Иммунитетны күтәрә торган коктейль

Кирәк: алма – 1 данә, теләсә нинди җиләк – 100 г, теләсә нинди яшел тәмләткеч (редис, борчак, руккола, кресс-салат) – 1/2 ст., имбир тамыры – 1 см, су яки үсемлек сөте – 100 мл.

Әзерләү. Барлык ингредиентларны блендерда вакларга, су яки сөт өстәп, яшел тәмләткечләр белән бизәп, табынга бирергә.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ГАЙБӘТ КАБЕРГӘ КЕРТӘ

Гайбәт – гөнаһ. Моның шулай икәнен белсәк тә, сөяксез тел еш кына сөйләвен белә тора. Күптән түгел Канада галимнәре гайбәт сөйләүдән тәм табуның сәбәбен ачыклаганнар. Баксаң, гайбәт сатканда кешедә күпләп мәхәббәт гормоны бүленеп чыга икән. «Кеше бу мизгелдә әйтеп бетермәслек ләззәт кичерә», – ди галимнәр. Ә гайбәт сатуның гөнаһын кая куярга?

Усад бистәсе мәчете имам-хатыйбы Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ белән гайбәт турында сөйләштек.

– Гайбәт сөйләү ислам динендә иң зур гөнаһларның берсе санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Кешедә булган нәрсә турында сөйләсәк, ул – гөнаһмы?» – дип сораганнар. Пәйгамбәр исә: «Әгәр сез анда булган нәрсә турында сөйләсәгез, бу гайбәт була. Әгәр аның турында булмаган нәрсә сөйләсәгез, ул ялган була», – дип җавап кайтарган.

:: Кеше ни өчен гайбәт сөйли?

– Күп очракта кеше хәсетлек аркасында гайбәт сата. Яхшырак булуның ике ысулы бар. Аның беренчесе – хакыйкатьтән яхшырак булу, нәрсәдер эшләү, тырышу, үзгәрү. Икенчесе башка кешеләрне түбәнсетүдән гыйбарәт. Ни кызганыч, арабызда күпләр нәкъ менә шушы соңгы алым бәрабәренә үзен яхшырак итеп күрсәтергә тырыша. Эшсезлек аркасында гайбәткә кереп китүчеләр дә бар. Кешене эштән алу, аның урынын яуларга тырышу кебек мәкерле ниятләр дә моңа сәбәпче булырга мөмкин. Гайбәт сатуга иң зур сәбәпләрнең тагын берсе – телеңне изгелектә эшләтмәү. Кешеләрне яхшылыкка өндәп, изгелек турында сөйләп, телен шундый яхшы ысул белән генә эшләткән кешенең гайбәт сатарга вакыты да, көче дә калмаячак.

:: Гайбәт тыңлау – гөнаһмы?

– Гайбәтне сөйләү генә түгел, аны тыңлау да – гөнаһ. Ник дигәндә, әгәр без кешегә гөнаһ эштә теләктәшлек күрсәтәбез икән, үзебез дә гөнаһлы булып саналабыз. Әгәр кеше гөнаһ эшләгәндә урында басып, карап торса, гайбәт сөйләгәндә аны тыңлап утырса, димәк, ул аңа үзенчә бер көч-куәт биреп тора дигән сүз. Шуңа күрә кеше гайбәт сөйли башлый икән, аны шундук туктатырга кирәк. Бу – безнең вазыйфабыз. Әмма моны аңа тупас итеп түгел, хикмәтле, йомшак ысуллар белән аңлатырга кирәк.

:: Үзе турында гайбәт сүзе ишеткән кеше, гадәттә: «Сөйләсеннәр, гөнаһларым кимер», – дип тынычлана. Үз-үзеңне болай юату дөресме?

– Әгәр берәү кеше турында сөйләгәннән соң, килеп, аннан гафу үтенмәсә, яисә аның турында начар сүз сөйләгән урыннарда яхшылык сөйләп, шул кешегә хакын кайтармаса, Кыямәт көнне ул үзенә тиешле әҗер-савабын шул кешегә бирәчәк. Шуңа күрә үзең турында гайбәт ишеткәч: «Сөйләсеннәр», – дип әйтү дөрес түгел, әлбәттә. Бу аларны куәтләгән кебек килеп чыга. Без исә гөнаһларны сүздә дә, гамәлдә дә хупларга тиеш түгел. Шуңа күрә бу очракта: «Сөйләсәләр, киләчәктә әҗер-савапларын үземә бирерләр», – диярга кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Гайбәт кабер газабына илтә, диләр...

– Гайбәт сөйләү кабердә дә, Кыямәт көнендә дә газапка алып бара. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләре дә шуңа ишарәли. Кеше тәүбә кылып, гайбәт сөйләгән кешесеннән гафу сорамаса, аның хакын бу дөньяда хакламаса, ул, дөрестән дә, кабер газабына илтергә мөмкин.

:: Диндә гайбәт сөйләү рөхсәт ителгән очраклар бармы?

– Рөхсәт ителгән җирдә кеше турында сөйләсәк, ул гайбәт саналмый. Әйтик, берәүнең кызын кияүгә бирәсе килә дә фәлән егет турында сораша, ди. Бу очракта ул гайбәт саналмый. Кешене эшкә алганда элеккеге эшеннән аның турында мәгълүмат сорау да моңа керми. Әмма бу очракта да кеше үзен билгеле бер кысада тотарга тиеш. Аннан кеше турында эшкә бәйле мәгълүмат сораганнар икән, ул шул турыда гына сөйләргә тиеш. Артыгын сөйләргә кирәкми. Бу очракта инде ул гайбәткә әвереләчәк.

:: Гайбәттән ничек котылып була?

– Моның өчен иң элек гайбәт сөйләүдән туктарга кирәк. Алга таба Аллаһы Тәгаләдән гафу сорау зарур. Ходай Тәгаләгә: «Киләчәктә башка гайбәт сөйләмим», – дип вәгъдә бирергә кирәк. Аннары гайбәте сөйләнгән кеше янына барып, аннан гафу сорарга кирәк. Әгәр ул кешедән гафу сорагач, ара тагын да бозылырлык булса, кеше аның турында начар сүз сөйләгән җирләрдә яхшы итеп сөйләргә кирәк. Кыямәт көнендә бу да изгелек булып исәпләнәчәк.

Март аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Сиш	04:32	06:35	15:20	17:17	18:59
2	Чәрш	04:29	06:32	15:22	17:19	19:01
3	Пәнҗ	04:27	06:30	15:23	17:21	19:03
4	Җом	04:24	06:27	15:25	17:23	19:05
5	Шим	04:22	06:24	15:27	17:26	19:07
6	Якш	04:19	06:22	15:29	17:28	19:09
7	Дүш	04:16	06:19	15:31	17:30	19:11
8	Сиш	04:14	06:17	15:32	17:32	19:13
9	Чәрш	04:11	06:14	15:34	17:34	19:15
10	Пәнҗ	04:08	06:12	15:36	17:36	19:18
11	Җом	04:05	06:09	15:38	17:38	19:20
12	Шим	04:03	06:07	15:39	17:40	19:22
13	Якш	04:00	06:04	15:41	17:42	19:24
14	Дүш	03:57	06:01	15:43	17:44	19:26
15	Сиш	03:54	05:59	15:45	17:46	19:29
16	Чәрш	03:51	05:56	15:46	17:48	19:31
17	Пәнҗ	03:48	05:54	15:48	17:50	19:33
18	Җом	03:45	05:51	15:49	17:52	19:36
19	Шим	03:42	05:48	15:51	17:54	19:38
20	Якш	03:39	05:46	15:53	17:56	19:40
21	Дүш	03:36	05:43	15:54	17:58	19:42
22	Сиш	03:33	05:40	15:56	18:01	19:45
23	Чәрш	03:30	05:38	15:58	18:03	19:47
24	Пәнҗ	03:27	05:35	15:59	18:05	19:50
25	Җом	03:23	05:33	16:01	18:07	19:52
26	Шим	03:20	05:30	16:02	18:09	19:54
27	Якш	03:17	05:27	16:04	18:11	19:57
28	Дүш	03:14	05:25	16:05	18:13	19:59
29	Сиш	03:10	05:22	16:07	18:15	20:02
30	Чәрш	03:07	05:20	16:08	18:17	20:04
31	Пәнҗ	03:04	05:17	16:10	18:19	20:07

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йәгез, бер дога!

Матур төш күрү өчен укыла

«Нүәмину билләәһи нәсику – билләәһи нәрудду үмүүранәә иләллааһи вә хәсбунәллаһу вә нигъмәл-вәкиил. Вә ләә хәулә вә ләә куввәтә илләә билләәһил-галиййил-газыйим».

Мәгънәсе: «Аллаһыга ышанабыз. Эшләребезне Аңа тапшырабыз. Аллаһ – нинди гүзәл вәкилдер! Аңардан башка көч һәм куәт иясе юктыр».

Иң начар әйбер

Нәүширван хаким өендәге җыелышта өч хикмәт иясе дә катнашкан. Сөйләшү барышында иң начар әйбернең нәрсә булуы хакында сүз купкан.

Грек хикмәт иясе:

– Иң авыр һәм начар әйбер ул – мохтаҗлыкта картаю, – дигән.

Һинд хикмәт иясе:

– Иң авыр һәм начар әйбер – кайгы-хәсрәт белән бергәлектә авыру килү, – дигән.

Бәзер Җөмһүр исемле хикмәт иясе:

– Иң авыр һәм начар әйбер – начар гамәлләреңә күп булган хәлдә үлем килү, – дип әйткән.

Калган хикмәт ияләре Бәзер Җөмһүрнең хаклыгын танып, аның фикерен кабул иткәннәр.

Нәсыйхәт:

Бу, чыннан да, шулай, чөнки калган хикмәт ияләре искә алган хәлләрдән чыгу юлы бар, алардан котылып була. Әмма үлеме якынаеп килгән чакта бик күп начар гамәлләре булган кешенең хәле начар. Аның начарлыкларын изгелекләргә алыштырырга вакыты юк. Әгәр инде начар гамәлләренең берсе көферлек булса, моннан бөтенләй дә качу юлы булмас. Аллаһым сакласын!

«Рухуль Бәйан» китабыннан

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

АРТУР ШӘЙДУЛЛИН:

«АКТЕРНЫҢ СЕРЕ БУЛЫРГА ТИЕШ»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка Камал театры артисты Артур ШӘЙДУЛЛИНны дәштек. Театрдагы үзгәрешләр актерга ничек тәэсир итә? Оста итеп бии белү Артурга ничек ярдәм итә? Без әнә шулар турында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Бар да яхшы, Аллага шөкер.

:: Камал театрында эшли башлавыгызга ничә ел инде?
– Театрыбызда тугызынчы елымны эшлим. Студент елларын да кушсам, 13 елга тула.

:: Үзегезне яшь актер дип саныйсызмы, әллә инде тәҗрибәлерәкләр исемлегенә кертәсезме?
– Үземне урта буын, олпат артистларыбыз исемлегенә кертә алмыйм. Балалар белән дә эшләгәнгәдерме, гел хәрәкәттә булгангадырмы, үземне 16–17 яшьлек егет итеп хис итәм. Ә бу сорауга болайрак җавап бирим әле: мин – тәҗрибәле яшь актер.

:: Камал театрының яңа бина проектын ошаттыгызмы? Ничек уйлыйсыз, актерлар күченүне ничек кичерер?
– Бик ошый. Беренче күрүдә үк архитектурасын, бина проектының заманча булуын ошаттым. Билгеле, күченү җиңелләрдән булмас, ләкин ул авырлыклар да озакка сузылмас дип ышанам. Театрда эшләүче актерлар һәм, гомумән, бөтен персонал өчен яхшы булсын дип тырышалар бит, эшләве күпкә җиңелрәк булыр дип уйлыйм.

:: Актер өчен үзгәрешләр файдагамы?
– Кеше бер урында таптанса, үсеш турында уйламый, димәк. Актерлар өчен үзгәрешләр аеруча мөһим. Төрле режиссерлар белән эшләүне генә алыйк. Һәр режиссерның үз карашы, үз стиле бар. Кемдер күбрәк формага, икенче берәү – пьесага, өченчесе актерга басым ясый. Боларның барысы да – актерга яңа тәҗрибә туплау өчен менә дигән мөмкинлек.

Эштә генә түгел, яңалыклар һәр өлкәдә булып торырга тиеш, минемчә. Тормыш бит ул чишмә кебек – гел агып тора, юнәлешен дә үзгәртеп ала. Тарихны алсаң да, бар нәрсә дә мәңгелек түгел. Иң мөһиме – уңай үзгәрешләр күбрәк булсын.

:: Сез – оста биюче дә. Шулай да, театрда эшләүне өстен куйгансыз...
– Актер булу минем балачак хыялым иде. Ә бию сәләте театр училищесында укыганда гына ачыкланды. Моңа кадәр, биюгә, хәрәкәткә карата мәхәббәтем булса да, эчтә ташып торган энергияне дөрес итеп чыгара белмәгәнмен. Ләкин мин үземне биюче дип әйтә алмыйм. Мин – актер. Ә бии белү актерга бик ярдәм итә. Гомумән, безнең һәрберебезнең көчле ягыбыз була. Кемдер оста итеп сөйли, кемдер җырлый, кемдер менә бии.

:: Профессиональ биюче булу теләге юкмы?
– Мин болай да үземне тонуста тотам. Бию – минем икенче иппием, диярге дә була. Чөнки хәзер мин булган белемнәремне балаларга өйрәтәм.

Блиц-сораштыру:

– Хәзерге вакытта нинди китап укыйсыз?
– Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» романын.
– Нинди роль башкарырга телисез?
– Шекспирның Гамлетын яисә Фаустның Мефистофелен уйнар идем.
– Бию өйрәнү һәм сүзләр ятлау. Кайсы җиңелрәк?
– Икесе дә бертигез кебек. Ләкин бию өйрәнү якынрак миңа.
– Сез башкарган рольләрнең кайсын тамашачы аеруча үз итте дип уйлыйсыз?
– «Бию пәрие»ндәге Сәйдәш образы. Мин анда үземне-үзем уйныйм кебек. Сюжеты да нәкъ минем тормышка якын.
– Иң зур хыялыгыз?
– Дөнья буйлап сәяхәт итәр идем – әлегә шул турыда хыялланам.
– Актер булмасам...
– ...иҗат юлын сайлар идем. 11 нче сыйныфта укыганда миңа барысы да: «Сиңа артист булу нигә кирәк?», «Аларның бит акчалары юк!», «Башка һөнәр сайла», – диде. Шушы сүзләрне тыңлап, мин хәтта икътисадчы булырга әзерләнә башлаган идем. Соңыннан үзәмә тугры калдым.

:: Иҗат кешеләренә бераз сәерлек хас, диләр. Килешәсезме?
– Килешәм. Мин моны нормаль хәл дип кабул итәм. Иҗат кешеләре башкалардан аерылып торырга тиеш инде ул. Менә мин, мәсәлән, бераз сәер киенәм. Ләкин бу да кешегә ошарга яисә ошамаска теләүдән түгел. Киемне мин үз теләгемнән чыгып һәм кәефемә карап сайлыйм.

:: Татар театрының бүгенге хәле турында да сөйләшик әле.
– Безнең театр бүген хәрәкәттә. Бу – әлбәттә, театрның киләчәге өчен уңай күренеш. Экспериментлар, төрледән-төрле лабораторияләр дисеңме, яңа проектлар, формалар эзләү – барысы да бар. Шулай булгач, татар театры озак яшәр дигән өмет тә бар.

:: Шәхси тормышыгыз турында сөйләшергә, аны күрсәтергә яратмыйсыз шикелле.
– Беләсезме, спектакль тәмамланып, театр капкасыннан чыгуга, мин актер Артур Шәйдуллин түгел, мин гап-гади Артурга әйләнәм. Ягъни тормыш белән театрны аерып карарга тырышам. Шуңа да халык минем шәхси тормышымны түгел, бары тик башкарган рольләремне генә күрә. Барын да күрсәтеп торсаң, аның кызыгы да бетәчәк. Актерның кечкенә булса да сере калырга тиеш.

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уеныбызның чираттагы өлешен тәкъдим итәбез. Бу юлы да эстрада артистларының популяр җырларын ни дәрәҗәдә белүегезне тикшерәчәкбез. Кагыйдәләре дә шул ук: җыр һәм җырчының төгәл исемен +7 (904) 718-14-69 номерына язып җибәрергә кирәк булыр. Җиңүчегә бүләк – телефонына 100 сум акча!

*Ике атна элеккеге санда чыккан уенда дөрес җавапны беренчеләрдән булып Сабадан **Илгизә Мөбарәкҗанова** җибәрде. Афәрин! Рәсемнәр астына без Закир Шаһбанның «Син – минем иң соңгы сөюем», Филүс Каһировның «Кышкы романс» җырларын яшергән идек.*

Күз төсе белән керфекләрне чагыштырудан башлана әлеге җыр. Яшьлек мәхәббәтендә икәү бергә янарга өнди ул.

Әлеге җырны башкаручы, чишмәгә тезләнеп, сулар эчсә дә, сагыну хисләрен баса алмый. Кыр өстеннән искән җилләрен дә юксына ул.

Әлеге җыр яшьлек белән күк җисемен чагыштыра. Яшь гомерне дә, менә шул күк җисемен дә тотып калып булмый, ди җырчы.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

2 март | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
Мамадыш районының Түбән Тәкәнеш авылында яшәүче 13 яшьлек Самирә Рәхимова оста итеп калфак чигә. Әлеге эшкә ул 11 яшендә тотынган. Кечкенә кызны бөтен республикада беләләр хәзер. Ул ясаган калфакларны күпләр кия. Оста куллы кызның әнисе дә кул эшләренә һәвәс икән.

– Минем әбием бик оста иде. Ул безне кечкенәдән кул эшләренә өйрәтте. Әбинең сандыгы әле дә өебездә кадерле истәлек булып тора, – ди Самирәнең әнисе Ильмира ханым. – Икенче кызым беренче сыйныфта укыганда бер бәйгедә катнашырга булды. Без аны әзерли башладык. Күлмәген дә тектек, тик калфак юк. Кая гына бармадык, табып булмады. Шуннан соң Самирә белән бергә утырдык та калфак чигәргә булдык. Бу эш кызыма ошап китте. Мин гел үсендереп торырга тырыштым, булдырасың, дию балама көч бирде. Ул ясаган калфаклар берсеннән-берсе матуррак килеп чыга хәзер.

Ильмира Рәхимованың шәхси архивыннан

Самирәнең үзе белән дә сөйләштек. Әлегә кул эшләренә ял көннәрендә һәм каникулда гына алына икән. Калфакка заказларны җәй көне ала. Кечкенә кызның кул җылысы белән эшләнгән калфакларны Сарман районының мәдәният өлкәсендә эшләүчеләргә дә җибәргәннәр, Мамадышка, килгән туристлар да сатып алып киткән.

– Киемнәрне чигеп бизәргә яратам. Әле менә футболкаларга, акча янчыгына милли бизәкләр ясый башладым. Калфакны бәрхеттән тегәм, аннары төрле сәйләннәр белән бизим. Алтын җепләр белән дә чигә беләм. Бизәкләрне алдан төшермим. Кулларым үзе белеп чигә, – ди ул. – Калфак, түбәтәйләр чигәргә интернеттан оста Луиза Фәсхетдинованың кул эшләреннән карап өйрәндем. Аның түбәтәйләрен Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та кия бит. Әле миңа чын оста булыр өчен бик күп тырышырга кирәк. Самирә районда узган бәйрәмнәрдә калфакларын сата икән. Узган ел Сабантуйда кул эшләрен сатып, үзенә кесә телефоны алырлык акча эшләгән. Кызның һөнәрләре моның белән генә бетми. Ул бик оста итеп рәсем ясый, тортлар да пешерә икән.

– Кулың эш белү рәхәт икән ул. Кыз кеше оста булырга тиеш дип уйлыйм. Ничә төрле һөнәр белсәң дә, күп түгел, – ди кечкенә кызчык. – Әниебез бар эшкә өйрәтеп үстерә. Мин исә, үзем акча эшли алгач, чигә белүем белән бик горурланам. Әлегә үскәч кем буласымны төгәл әйтә алмасам да, чигүне ташламаячагымны бик яхшы беләм.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РЕКОРДСМЕН ЭЛЬМИР

Кукмарада яшәүче 25 яшьлек Эльмир Хаҗиев, идәннән күтәрелеп, линиянең икенче ягына сикерү буенча Гиннесс рекордлар китабына кертелгән. Ул бу күнегүне 30 секундта 53 мәртәбә ясый. Егет әле моның белән генә тукталып калырга җыенмый.

Тагын да зуррак уңышларга ирешергә тели ул. Спортчы барысын да сөйләргә ашыкмый: сер булып калсын, ди. Әмма бер зур теләген әйтте: «Русский ниндзя» тапшыруында катнашып җиңәсе килә аның.

– Әтиемнең арабыздан иртә китүе мине мөстәкыйльлеккә, тырыш, үҗәт булырга өйрәтте, – ди Эльмир. – Әниенең сүзләре дә этәргеч булды. «Бөтен таянычым син», – диде әни. Шуңа күрә сынатмаска, әниемнең йөзенә кызыллык китермәскә тырыштым. Мин кечкенәдән бер урында тыныч кына басып та тора белмәгәнмен, гел сикерергә торганмын. Алтынчы сыйныфта укыганда әнием мине районадгы «Зилант» спорт мәктәбенә алып барды. Башта баскетбол уйнадым. Аннары инде спортның башка төрләрендә үземне сынап карадым. Бокс ошады.

Эльмир ул чакта спорт белән генә шөгыльләнми, укуда да алдынгы була. Россиякүләм олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар яулый. Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәүгә китә. Анда укырга керә.

– Югары уку йортында укый башлагач, йөгерә башладым. Халыкара марафонда катнашып, беренче килдем. Бу җиңү мине тагын да канатландырды. Үзеннән-үзе кул сугышына кереп киттем. Күп кенә турнирларда катнашып, Россиянең спорт мастеры исемен алдым. Күңелдә рекорд куясы килү теләге бар иде. 2019 елда идәннән күтәрелү буенча үземне сынап карарга булдым. 30 секунд эчендә сул кул белән идәннән 42 тапкыр күтәрелдем. Шунда Россия рекордчысы исемен бирделәр, – ди Эльмир.

Әлеге җиңүен күреп, дуслары тукталып калмаска киңәш итә. Шуннан соң ул интернеттан дөнья рекордчылары, Гиннесс рекордлар китабына керүчеләр турында укый башлый.

– Гиннесс рекордлар китабына эләгү өчен гариза, документларны өч тапкыр тапшырдым. Беренче тапкыр сул аякта һәм уң кулда күтәрелеп, бер минутка 49 тапкыр күнегү ясадым. Барлык документларны әзерләп җибәрдем. Әмма ике атнадан минем күрсәткечләрне узучы кеше барлыгын белдем. Шуннан соң икенче төрле итеп, идәннән күтәрелеп, линиянең икенче ягына сикерү буенча әзерләнә башладым. Бу күнегү алай авыр түгел, әмма тизлек кирәк. Рекорд куяр өчен тагын документлар җибәрдем. Тик видеоны күреп, гаебемне таптылар. Аркаң бөкрәйгән дигән кимчелек җиткерделәр, – ди ул.

Тик үҗәт кешене туктатып буламы соң? Эльмир үзенең күнегүләрен видеога төшереп, гаебен эзли. Гиннесс китабына керү теләге зур була аның. Тагын күнегүләр ясый башлый. Бу юлы өстәмә авырлык белән идәннән күтәрелүне сайлый.

– Бу күнегүне ясаганда бер аяк күтәрелгән һәм шул ук вакытта бөтен гәүдә туп-туры булырга тиеш. Әлеге күнегүне 30 секундта 53 тапкыр ясадым. Миңа кадәр 48не ясаганнар иде, – ди ул.

Бүген Эльмир Тыва Республикасында эшли. Кукмарага ял вакытында гына кайта. Әле киләчәктә тагын да зуррак рекорд куймакчы. Ул вакытында спорт белән дуслаштырганы өчен әнисенә дә, тренерларына да рәхмәтле.

– Һәр кешенең ниндидер таланты була дип уйлыйм мин. Әмма аны вакытында ача белергә кирәк. Тырыш булмасаң, бернинди уңышка ирешеп булмый. Хәзер малайлар бер-берсеннән начар гадәтләрне күреп, аларга охшарга тели. Ә мин бөтенләй киресенчә уйлый идем. Эчмәдем дә, тартмадым да. Үз юлымны таптым. Кечкенәдән башкалардан яхшы ягым

Эльмир Хаҗиевның шәхси архивыннан

белән аерылып торасым килде, – ди ул. – Малайларга киңәшем шул: вакытыгызны спорт залларында уздырыгыз. Спорт ул – сәламәтлек кенә түгел, тормыш авырлыкларын җиңәргә өйрәтә, рухи яктан көчле дә итә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҖЫЛЫ ЙОРТ

Биредә каты авыруларның хәлен җиңеләйтергә тырышалар, җаннарын да дәвалыйлар, аларны үлемнән курыкмаска өйрәтәләр. Дәваланучылар да белә: алар кадерсез түгел, кирәкле. «ВТ» хәбәрчесе Казан хосписында булып кайтты.

Мең рәхмәт!

Әлеге хосписка беренче генә килүем түгел. «ВТ» укучылары хәтерлидер әле: биредә сукмак яман шеш белән авыручы Айгөл Фазыйлова яшәгәндә салынды. Айгөлнең хәлен белергә килгәндә үк, әлеге йортта җылы тапкан бик күп кешеләр белән аралаша идек.

Янә шул сукмактан атларга туры килде. Берни үзгәрмәгән. Газетадан икәнне белгәч, юл күрсәтеп озатып калдылар. Мин «Кышкы бакча» дип аталган залга килеп кердем. Биредә еш кына бәйрәмнәр үткәрәләр. Бераз гына эчкәрәк үткәч, балалар ята торган бүлек башлана. Күңелгә авыр булып китсә дә, бүлмә ишеген шакыйм. «Керегез», – дигән тавыш сискәндереп җибәрә. Бу бүлмәдә Тәтеш районыннан килгән Сидоровлар яши икән.

– Улымда – ДЦПның катлаулы төре, – ди Владиславның әнисе (ул үз исемен күрсәтмәүне сорады. – **Г.Ш.**). – Моңа кадәр дә күп кенә тернәкләндерү үзәкләрендә йөри идек. Җиде ел элек танышларым хосписка барып карарга киңәш бирде. Мондагы тәрбия һәм дәвалану башка җирдәгедән аерылып тора. Биредә авыруларга бөтенләй башка караш. Бала да үзенә карата җылы караш, ярату тоя. Без – әниләр дә, балаларыбызга булган мөнәсәбәтне күреп, шатлыктан елыйбыз хәтта. Сабыйның сызлануын күрү бер дә җиңел түгел бит.

Икенче бүлмәдә 12 яшьлек Владимир Жаворонков яши. Ул да биргә әнисе белән килгән. Табиблар, тугач та, 1 ай гына гомере бар, дисәләр дә, малай киресен исбатлаган. Ятып кына торачак дигәннәре дә хак булмаган.

– Улымда – нерв авыруы. Ул авыру булып тугач, ирем ташлап китте. Әни миңа эти дә, әни дә булырга туры килде. Башыңа төшкәч, түзәсең икән ул. Үксеп елаган чакларым да күп, әмма яшәргә кирәк. Авыру балам белән башка кияүгә чыга алмадым. Бар юанычым, тормышымның яме – улым, – ди әнисе Рузанна. – 3 ел элек безне бер хәйрия фонды биргә бәйрәмгә чакырды. Килдек. Ул чакта читтән генә күзәттем. Улым төсле авырулар да бар иде. Биредә дәвалансаң иде дигән теләк туды. Бәйрәм беткәнне дә көтеп тормадым, баш табиб урынбасары янына бардым. Ун көннән без монда идек инде…

Әле өмет сүнмәгән

Хосписта олылар да ята. Барысы да яман чир белән көрәшәләр. Араларында караучысыз калганнар да, биргә балалары китергәннәре дә бар. Хоспистагы иң өлкән кеше – 93 яшьлек Евдокия түти Бөек Ватан сугышында катнашкан. Монда 3 ел яши икән инде. Алып килгәндә, үзе йөри дә алмаган. Хәзер инде әкренләп аякка баскан. Бердәнбер улының үлгәнен белми әле ул. Улы килеп алып китәр дип яши.

– Ашаталар, эчертәләр. Даруларын бирәләр. Юындыралар да. Мин мондагы кебек яратуны, назны, кадер-хөрмәтне беркая да күрмәдем. Бу йортта миңа рәхәт. Үләсе дә килми, – ди ул.

Илсур Сибгатуллинга – 59 яшь. Ковид белән авырганнан соң, сәламәтлеге начарланып киткән. Сулыш алу кыен икән. Өйдә кислород аппараты белән генә яшәгән. Биргә килгәч, авыруы артка чигенгән.

– Монда эшләүчеләрнең яхшы мөнәсәбәте күңелгә өмет бирә. Әле өмет сүнмәгән. Бер дәваланып чыккач, 2 ай рәхәт яшәдем. Тыным да бетмәде. Менә тагын кердем әле. Үземне рәткә китерәсе килә, – ди ул.

Кама Тамагыннан Рәшит абый биредә 1 елга якын ята икән инде. Хатыны да янәшәсеннән китми. «Без аларга карап сокланабыз. Яратуның көче шушыдыр. Иренең хәле авырайды инде. Ул кешеләрне танымый. Хатыны аны бер минутка да ташламый», – ди хосписта эшләүчеләр.

Бу хакта сөйләү авыр

Монда ятучыларны күргәч, ирексездән күзләр яшьләнә. Күңелдә кызгану хисе туа. Ничек тә ярдәм итәсе килә үзләренә. Тик бу мөмкин түгел… Анжела Вавилова фонды рәисе Владимир Вавилов, әйтүенчә, кешеләргә тиздән үләсен хәбәр итү – иң кыены.

– Без каты авырудан интегүчеләрнең тормышын җиңеләйтергә тиеш. Шуңа да Татарстанда паллиатив ярдәмне киңәйтмәкче булабыз. Паллиатив ярдәм – кешегә тормышының соңгы мизгелләрендә ярдәм итү дигән сүз. Кулымнан килсә, мөмкинлегем җитсә, мин республиканың һәр районында хоспис ачар идем. Максатым бер: соңгы сәгатен көтеп яткан кешеләрнең авыруларын оныттырып, аларга ярату бирәсе килә, – ди ул. – Кайбер чирләрне дарулар да басмый башлый. Әнә шул чакта хоспис кебек җир кирәк. Биредә без медицина ярдәме белән берrәттән психологик ярдәм дә күрсәтәбез. Еш кына безгә авыруларга тиздән якты дөньядан китәселәрен әйтергә туры килә. Өлкән яшьтәгеләр бу сүзне кабул итә әле. Ә менә яшьләргә әйтү үземә дә авыр, аларга да читен. Без бит кешенең күпме яшисе калганын беләбез. Юридик эшләрен башкарып өлгерсен дип, әйтергә тырышабыз. Кеше үз аңында булганда кирәкле документларга кул куеп, мирасын тапшырып калдырырга тиеш. Алайса, бездә бер стакан су бирергә кеше булмаса да, авыру үлгәч, аның байлыгын эзләп йөрүчеләр шактый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Владимир Вавилов, биредә ятучыларның – үз дөньясы, ди.

– Бездә берәү дә моңсуланмый. Биредә тормышны яратып яшиләр. Күрше бүлмәләрдә ятучылар никах та укытты хәтта. Розаның бер атна яшисе калганын белгәч, үзләре шулай хәл итте. Без исә каршы килмәдек. Биредәгеләрнең һәр теләген үтәргә тырышабыз, – ди ул. – Мин хосписта ятканнарның һәркайсын хәтерлим. Исемдә тотам. Ләйсән исемле Чаллы кызы бар иде. 5 яшендә танышкан идек. Былтыр 22 яшен тутырып үлеп китте. Чибәр кыз иде. Рәсем ясарга яратты. Миңа истәлек итеп бер картина ясады. Анда өч бүре сурәтләнгән. Мин кыздан сорыйм, нигә бүреләр соң, дим. «Болар – яшәр өчен көрәшүчеләр», – дип җавап бирде. Шул картина минем бүлмәмдә тора.

Владимир Вавилов баштарак Казанда хоспис ачарга кирәклеген әйткәч, аны аңламаучыларның күп булганын искә ала.

– Авыруларны бары тик онкология диспансерында гына дәвалап була дип уйлыйлар иде. Ә без ялгышмадык. Аларга соңгы көннәрендә дәвасын да, өй шартларын да бирә алабыз. Безнең тәҗрибәне күрергә Россия төбәкләреннән дә, чит илләрдән дә киләләр хәзер. Әле менә шушы көннәрдә Кырымнан килеп киттеләр. Алар да үзләрендә хоспис төземәкче, – ди ул.

Ярату кирәк!

Бер йөрәккә күпме ярату, наз, хәсрәт сыйган. Владимир Вавиловның авырулар турында яратып сөйләвен, аларның һәркайсын исемләп белүен, ул гына түгел, инде вафат булган кешеләрнең туганнары белән элемтәдә торуын күреп, аның никадәр кешелекле икәненә тагын бер кат инанасың. Ирексездән: «Болай яшәү авыр түгелме?» – дигәнемне сизми дә калдым. Ә ул исә: «Бу – минем яшәү рәвешем», – дип, җавапны кыска тотты. Ә бит үзенең дә күңел капчыгы буш түгел. Ике кызын салкын җир куенына салган кеше ул. Әмма шуңа да карамастан, ул әле дә башкаларны уйлый. Әллә нинди хыяллар белән яши. Озакламый төзелеп бетәчәк икенче хосписка да өмете зурдан. Икенче хосписта 60лап урын булачак икән. Анысы – өлкәннәргә, искесе балаларга булачак.

Әлегә биредә дәваланучы сабыйларның саны 250гә җитә. Бер-бер артлы чиратлап килеп торалар. Казанның Дәрвишләр бистәсендә урнашкан психоневрология диспансерында әти-әниләре ташлап калдырган 50ләп сабыйны да монда алып килеп, дәвалап, тәрбияләп җибәрәләр икән.

Ярдәм кирәк сабыйларны әниләре хосписка алып килә ала. Хәтта яңа туган сабыйларын да биргә китерәләр икән. Монда яшәү өчен акча түлисе түгел. Һәр баланы 21 көн дәвалыйлар. Әгәр сәламәтлеге буенча тагын да дәвалау кирәк икән, ул тагын яшәп кала.

– Бездә дәвалану бушлай. Алайса, күп кеше акча түлисе була дип уйлап ялгыша. Без иганәчеләр ярдәме белән яшибез. Әгәр кеше тели икән, акча күчерә ала. Әмма мәҗбүриләү юк. Без авыр хәлдә калган һәр кешегә ярдәм итәргә әзербез. Бу хакта районнарга баргач та сөйлибез. Соңгы минутларын җылыда, яратуда уздырасы килгән һәр кешегә безнең ишек ачык, – ди ул.

Хоспис белгечләре авыруларның өйләренә барып та ярдәм күрсәтә. Әлеге ярдәмне алу өчен паспорт, табиб белешмәсе, медицина полисы, инвалидлык кәгазе, СНИЛС кирәк. Табибларны өйгә чакыру тәртибен хосписка шалтыратып белешергә була.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КЕМНӘР БАРА АЛА?

➤Яман чирнең соңгы стадиясе белән көрәшүчеләр яки аларның якыннары.
➤Дәвалый алмый торган авыруы булган кешеләр.
➤Вакытлыча дәвалану алу өчен физик мөмкинлеге чикләнгән 18 яшькәчә балалар.

ХОСПИСТА ЯТУ ӨЧЕН НИНДИ ДОКУМЕНТЛАР КИРӘК?

➤Балаларның туу таныклыгы, зурларга – паспорт;
➤табибтан юллама;
➤медицина полисы;
➤амбулатор картадан авырулары хакында белешмә;
➤дәвалаучы табибтан белешмә;
➤14 яшьтән соң RW анализы;
➤өй эчендәге эпидемиолог шартлар турында соңгы 3 көндәге белешмә;
➤бала белән ятучы әти-әнигә һәм авыруның якыннарына флюорография үтү турында белешмә кирәк булачак.

КАЯ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ?

➤Районда яшәүчеләр хоспис турында үзләрендәге хастаханәнең баш табибына;
➤табиб-онкологка.

Казан хосписы (**angela-vavilova.ru**) сайтында да кирәкле мәгълүматны табып була. Барлык сорауларга җавапны хосписның кабул итү бүлегеннән **8 (843) 237-75-66** телефон номеры аша белешә аласыз.

ИЛТӨЗӘР МӨХӘММӘТГАЛИЕВ:

«БИТЛЕКНЕ САЛЫР ВАКЫТ ҖИТТЕ»

Камал театрының кече сәхнәсендә гайре табигый шигъри кичә булды. Аның авторы һәм төп герое Илтөзәр Мөхәммәтгалиев, кулына акбур алып, такта янына басып, күңелгә үтеп керә торган шигырьләрнең һәм музыканың, табигать күренешләренең гармония законына буйсынуын аңлатты. Саннар һәм формулалар ярдәмендә. Дәрес чын шигърият, музыка белән үрелеп барды. Әгәр бу кичәне театрның бер юнәлеше дип алсак, аның барлыкка килү сәбәпләре нәрсәдә? Театр тамашачыга сабак бирергә соңга калмадымы? Шигърият һәм юморда уртаклыклар бармы? Татарстанның атказанган артисты Илтөзәр МӨХӘММӘТГАЛИЕВ белән шушы хакта сөйләштек.

:: Илтөзәр, узган атнада «Киек каз юлы» шигъри кичә премьерасы булды. Тамашачыны фәлсәфи һәм интеллектуаль әңгәмәгә чакыру – хәзерге заманда зур кыюлык. Алар күбрәк шоуга, күңел ачуга күнеккән бит. Тамашачы аңламас дигән шик булмадымы?

– «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дигән бит Тукай да. Тамашачыны да укмаштырып, бер калыпка салып карарга ярамый. Алар төрле. Зур залларда бара торган шоуларны ярата торганы да, кече залда бер дулкында тибрәлә ала торган иҗади тамашачы да бар. Халыкның төрлесен сайларга, теләгәнен таләп итәргә хакы бар. Ә үз дөньясы белән яши торган тамашачы ул гел булды һәм булачак. Аларны бергә туплап, күңелләрен күрәсем килде. Ниятем барып чыкты сыман. Ник дигәндә, бер кешенең дә телефоны шалтырамады, андый хәлне ничә ел күргәнем юк иде инде. Бер генә кешенең телефоны балкып алды, анысы да миңа күңелемдәгене җиткерергә ярдәм генә булды. Тын калып, шигырь тыңлап утырдылар, бу – уртак кызыксынулар турында бергәләп сөйләшү булды дип уйлыйм.

:: Ни өчен гармония дәресе? Тормышта хаос өстенлек иткәнгәме әллә?

– Кайбер кеше хаос та яшәргә лаеклы дип яши һәм ялгышып, шуңа ияреп китә. Чынлыкта исә... әгәр дә хаос законы буенча барсак, дөнья, яшәеш булмас иде. Чөнки дөнья тынычлык, матурлык, гармония законнары буенча яши һәм башкача була да алмый. Хаос законы буенча китсәк, җир түгәрәк була алмый, кояш системасындагы хаос һәлакәткә китерер иде. Глобаль катастрофаларның булмавы, булган очракта да, кисәтү рәвешендә генә булуы – тәртипкә дәлил бит инде. Кайбер предметлар матур, чөнки гармония законына буйсына. Шигырь, музыка белән дә шул ук хәл.

:: Гуманитар белән төгәл фәннәрне аерып карауга каршы чыгуың аңлашыла, ә телләр, диннәр мәсьәләсендә фикерең нинди?

– Чикләр бит юк. Дөньяга һәрбер кеше мөселман булып туа дигән фикерне ишеткәнең бардыр. Аны ишеткәч, кешеләрне мөселманга һәм христианга бүлә башлыйлар. Ә бит аның мәгънәсе – иманлы, яхшы күңелле булып туа дигән сүз. Чикләр ул – коммерция. Бүленеш акча әйләнеше барлыкка килгәнгә пәйда була. Диндә дә, башка өлкәдә дә шулай. Димәк, проблема бездә, Аллаһы Тәгаләдә түгел. Адәшмәс өчен гармониядә яшәү генә кирәк. Дини китаплар исә – хаос булдырмас өчен ярдәмлек әсбаплар алар. Ислам дине, игътибар итсәк, иң артта калган илгә иңдерелгән. Күтәрелергә ярдәм итәр өчен. Тел аермалыгы исә күңел аермалыгы түгел. Күңел чисталыгы бөтен кешедә дә бер. Ярату – бер, күңел тартылуы – шул ук. Гармония законнары буенча язылган җыр икән, кеше, бу бит минем телдә язылмаган, дип уйламый, тыңлый һәм ләззәт ала. Конфессияләр, милләтләр, диннәр ярышы хаоска китерә. Тормышта алгы планга ярыш чыкты. Нәтиҗәдә тынычлык югалды.

:: Кичәгә рус поэзиясен кертү, башка телләрдәге музыканы ишеттерү бөтен кешедә дә яклау тапмас инде ул...

– Алай гына да түгел, бер кичә белән икенчесе эчтәлек буенча охшамаячак та әле. Шигырьләр, музыка үзгәрәчәк.

Хәтерлим, кечкенә чагымда әбием кич утырганда калын-калын китапларын чыгарып куя иде. Шуннан ахирәтләре белән гарәпчәне, фарсычаны, аннан мин аңласын өчен тәфсирен укыйлар иде. Нинди гыйлемле булганнар бит элек! Иске татар телендә «Кыйссаи Йосыф»ны укуны әйтмим дә мин. Элек бит гыйлем эстәүдә чикләүләр булмаган. Үзебезнең әдәби телгә кайтыйк. Гасыр башындагы кухня теле хәзер безнең әдәби тел санала. Ысулы җәдидчеләрнең хезмәте инде бу. Ә элек казахчаны да, гомумән, күпчелек төрки телләрне аңлаганнар. Чөнки шигырьне язылган телендә, ягъни оригиналда аңлау мөмкинлеге бар икән, тәрҗемәдә бирергә кирәкми. Поэзия тәрҗемәдә бигрәк тә очсызлана. Казахча, төрекчә, үзбәкчә, фарсыча да сөйли алам, ләкин аны кеше аңламаячак бит. Аңлаганы – шул рус теле бит инде.

:: Халык хәзер Европачарак фикерли дип әйтәсең киләме?

– Алай дисәң, мин Гамлетны, бик теләп, оригиналда укыр идем дә, залда нәрсә булачагын күз алдына китерәсеңме соң?

:: Чөнки беренче чиратта – мәгънәме?

– Авазлар яңгырашы да, сүзләрнең энҗе кебек тезелеп китүе дә. Форма, эчтәлек, иҗекләрнең гармониягә буйсынышы да. Әнә шундый үрнәкләрне тамашачыга җиткерәсем килә. Кайбер телләрне кабул итмәү – курку гына түгел, безнең комплекс та ул. Империяләр иртәме-соңмы барыбер таркала. Без иртәрәк таркалганбыз. Кем белә, бәлки яңадан чәчәк атарбыз. Мин моңа ышанам.

:: Авторларны ничек сайладың?

– Әйткәнемчә, кичә гомерле булса, авторлар алмашынып торачак. Гамил Авзал, Равил Фәйзуллин, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләм, Ркаил Зәйдулла, Йолдыз Миңнуллина һәм башка авторларның әсәрләре яңгырады. Үзем тойганча, үзем теләгәнчә. Чөнки пафосны, ясалмалыкны, кешегә ярарга тырышуны сөймим.

:: Шулкадәр авторны һәм дистәдән артык шигырьне истә калдыру өчен, нинди хәтергә ия булырга кирәк? Хәтерне яхшыртуның берәр сере бармы?

– Аның сере бик гади – ярату кирәк. Яраткан шигырь онытылмый.

:: Бу иҗади гаилә белән танышу кичәсе дә булды. Камал театрының иң талантлы артистларының берсе Ләйсән Рәхимованы тамашачы инде белә, ә менә кызың Ләйлә өчен дебют иде бугай.

– Кызым иҗади, эзләнүчән. Үрнәге белән ул үзе безне тәрбияли.

Ләйлә инглиз мәктәбен беренче репетиторсыз алтын медальгә тәмамлады. Инглиз теленнән 93 балл җыйды. Мин аны гаилә янчыгына иң зур кертем ясаучы дип тә әйтәм. Репетиторга 40ар мең сум түләмәгәнмен икән, әлеге акчаны ул эшләгән дип санала бит инде. Менә шундый кыз ул. 17 яшендә грант отып, Америкага китте. Бер ел укыганнан соң, студентлар кире илләренә кайта. Рәсем дизайны көллиятендә иң яхшы укучы саналганга, аны янә чакырып алып, җәмгысы 2,5 ел укырга рөхсәт иттеләр. Хәзер МХАТның сәхнә технологиясе һәм яктырту осталары мәктәбендә укый. Пандемия чорында онлайн укыдылар. Бөтенебез бикләнеп яши башладык берзаман. Шушы ярты елның бер атнасын ял иттем дә, эч поша башлады. Урамга да чыгарга ярамый бит әле. Кибеттән туфрак заказ биреп, балконда кыяр, помидор, үләннәр утырттык. Шул балконда чәй эчкән арада шигырьләр сөйләп йөрим. Ул арада Ләйлә фортепианода уйный башлый, Ләйсән җырлый. «Киек каз юлы» шулай яралды. Бу чир бетсә, икенчесе килер, күпләп җыелулар бетәр, менә шушындый фатир форматларына күчәргә туры килергә мөмкин дип уйлану җимеше дә ул.

> Битлекне салыр вакыт җитте. Ике ел бикләнеп ятканнан соң кеше гомернең кыска булуын һәм битлек киеп әрәм итәргә ярамаганын аңлады. Бу – мәгънәсезлек. Тамашачы күбрәк документалистикага тартыла. Аны ясалма сүз, ясалма уен, пафос белән җәлеп итеп булмый хәзер.

:: Тормыштагы Илтөзәр җитдиме, әллә шукмы?

– Тормышта кеше төрле була. Мин дә шулай. Кешесе туры килсә, рәхәтләнеп көләм, шаяртам. Алай якын кешеләрең белән генә эшләп була. Игътибар итсәң, кайбер кеше гел авыр вакытларын искә ала, сагышлана. Ни өчен ул үзен шушы халәттә тота? Чөнки сагышланганда ләззәт кичерә. Сагышлы җыр җырлаганда да шул халәткә керә. Кеше аны кайгыра дип уйлый, ә ул сагышлана. Кайгы ул – килгән вакытында кайгы, вакыт узгач, сагышка әйләнә. Ә инде күңелең катса, күздән яшь тә чыкмый, сагышланмыйсың да. Бусы куркыныч.

:: Заманнан алдарак бару хас икән сиңа. Кирәк вакытта «Хөршидә белән Мөршидә» чыкты. Хәзер кешегә тынычлык, Тукайча әйтсәк, «җанына мунча» кирәк. Гармония дәресе уйлап табылды.

– Хөршидәләр теге вакытта кирәк иде, вакыты узды, халык юморга туенды.

Блиц-сораштыру:

– Ирләр суган турагандa гына елыймы?
– Күз яше саф булса, ирнекеме ул, хатыннныкымы – анда аерма юк.
– Актер, сценарист, әти. Бу сүзләрнең кайсы иң якыны?
– Бала алдында мин әти, театрда – актер, өйгә кайтып, өстәл янына утырсам – сценарист. Бөтенесенә дә 100 процент булмышымны салам. Алар баланста.
– Тормыш кагыйдәң?
– Гомерне уйнап уткәрмә. Икейөзләнүне җенем сөйми.
– Өстәл китабың?
– Бу сорауны хәтта аңламыйм. Өстәл китабы белән генә чикләнгән кеше нинди була инде ул?
– Уйналмаган роль?
– ...-ләр ул. Рольләр.

:: Юмор дигәннән, татар юморының хәле хөрти бит, килешәсеңме? Бездә сәяси юмор, илдәге вазгыятьне сатира белән бирү дә күренми. Пародияләр билдән түбән төшеп китә дә менә алмыйча интегә...

– Хөршидәгә янә кайтсак, ул образларны без Радик Бариев белән җентекләп эзерләдек. Сүзгә кадәр, аның образы берәмтекләп туды. Аннан сүзе туды. Хәзерге номерларны алсак, авторлар аны җиңел акча эшләү юлы дип карый.

> Хәзер «шәһәр культурасы», «шәһәр татарлары» дип әйтергә бик яраталар. Кайда соң алар? Авыл татарларыннан көлмичә, аларны гаепләмичә күтәрергә кем комачаулый? Кем үстерде аларны? Инде авылда да татар калмады...

Юмор бар ул. Шигърият кичәсе шикелле кичәләр оештырасы көннәр булачак әле. Кеше әгъзалары тирәсендә кытыкланып йөрү – юмор түгел. Юмор – беренче чиратта интеллект. Ул булмаса, чыгыш әнә шул кытыклануга кайтып кала. Монда ник тамашачы карый дип тә гаепләп булмый. Чөнки «көтү психологиясе» дигән күренеш бар. Начар чыгышны берничә тапкыр карый яки ишетә икән, ул аны үзенә бәйсез рәвештә ярата башлый. Агулана.

:: Мәктәпләрдә вазгыять катлаулы. «Киләчәктә татар китабын укучы калырмы?» дигән сорау торган саен ешрак яңгырый. Мондый хәлдә театр нинди функцияне үти?

– Дәресләрне кыскартыр алдыннан мин бу киеренкелекне сиздем. Ул шартларга тиеш иде инде. Ләкин моны булдырмый калып та була иде. Татар теле сәгатьләрен дә калдырып, вакытын да кыскартып була иде. Кечкенә кызым Зилә сыйныфын алыйк. Кич җиттеме, сыйныфлары белән Зиләгә татар теле буенча өй эшеннән ярдәм сорап язалар иде. Аны эшләгәндә үзем дә авыр хәлдә калам: җөмлә төзелеше шундый катлаулы, ул биремне эшләргә бик озак вакыт кирәк. Ә бит математика, рус теле һәм башка фәннәр дә бар. Таләп итү авыр түгел ул, аны бит эш барырлык итеп таләп итәргә кирәк. Кыскасы, ахыры начар буласы билгеле иде. Шуннан, тукта әле, нишләп була, дип уйлый башладым. Алты сәгать вакыты да калсын, балаларга кызыклы булсын, вакытлары да бушасын. Безнең, җыр, хезмәт, физкультура дәресләре бар. Боларны татарча итеп була. Аның татарча булуыннан дәрескә бернинди хилафлык та килми. Рәсемнән яки музыкадан сәләте бар икән, бала мәктәптәге дәрес белән генә чикләнми, музыка һәм сәнгать мәктәбенә укырга керә, профильле белем ала. Шуңа күрә, тыю карары чыкканчы, нәкъ бер ел элек шушы тәкъдим белән Мәгариф министрлыгына киттем. Моны министр хәл итми дип җавап бирделәр. Шул чакта туктап калганыма үкенәм хәзер. Разил Вәлиевкә дә, башка комитетларга да барасы калган икән. Хәзер кайсыдыр мәктәптә музыка, хезмәт дәресләрен татарча укытуны кулланалар икән. Билингваль мәктәптә бугай.

Вазгыять чынлап та катлаулы. Болай барса, китап укучы, театрга йөрүче дә калмаска мөмкин. Шуңа күрә китапка якынайта торган, шигъри тамаша булсынмы ул, башка форматмы – бик кирәк. Тамашачы бер генә шигырьне яратып кайтып китсә дә, ул авторның китабын эзләп табачак.

:: Театрда үзеңне нинди рольдә, образда күрәсең? Тамашадан соң, укытучы дигән хис кала.

– Укытучы була алсаң, әйбәт әле ул. Табиб белән укытучыдан да изгерәк һөнәр юк бит ул, чынлыкта. Чын укытучылар бик аз калды. Мәгариф системасы, ай-һай, какшады. Ә укытучы – бик зур сүз ул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

СОВЕТ МУЛЛАСЫ

ХИКӘЯ

Фирдүс Гыймалтдинов – журналист, язучы, «Татарстан» ДТРК директоры. Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә уткәрелгән әдәби бәйгенең «Роман» номинациясендә «Урда ханы Үзбәк» романы белән икенче урынга лаек булды.

Гарәпша сыңар күзен ачты. Өйдә тыныч, тәрәзәдәге чәчәкле өлеңгәләр аша кечкенә генә йортларына якты кояш нурлары сибелгән. Карчыгы Шәмсекамәр инде торган, күрәсең, тавыкларга җим бирергә дип үк чыгып киткәндер. Мич артында кыштырдаган тавышы ишетелми.

Гарәпша биек сәкедән йон оекка төрелгән аякларын салындырып утырды. Урамда эссе җәй булуга карамастан, шулай җылы киенеп йокларга өйрәнгән шул ул. Тик соңгы вакытта йокысы бигрәк тирәнәйде. Хәерлегә генә булсын инде. Элек шылт иткән тавышка да сискәнеп уяна иде, хәзер менә карчыгының шыгырдавык ишектән чыкканын да ишетми калган. Картлык шушыдыр инде. Сабыйлыкка күчү галәмәте. Колак катылана, күзне инде әйтәсе дә юк...

Ул, кулы белән тәрәзә төбен капшап, анда торган кырлы стаканны тапты, җәһәт кенә аның эчендәге пыяла күзне алып, тиешле урынына урнаштырды. Илле елга якын яши бит шушы нәрсә белән. Фронтта яраланып, нәкъ күз карасын снаряд кыйпылчыгы айкап уткәч, табиблар аңа исән калуы өчен рәхмәт укырга киңәш итте. Сул күзенең иминлегенә өмет юк та юк, диделәр. Ул снаряд да 1944 елның кышына кадәр көткән бит, әй! Инде, гаскәрләргә ияреп, дерелдәп калтыранып йөгергән машинасында Берлинга ук барып керермен дип уйлап йөри иде, бер мизгел эчендә бу хыяллары чәлпәрәмә килде. Госпитальдән, күпме генә ялварса да, Гарәпшаны кире фронтка җибәрмәделәр, тиешле кәгазьләрен кулына тоттырып, өенә кайтырга куштылар. Бигрәк тә үкенечле тоелды аңа бу кайтуы. Ләкин гаскәр җитәкчеләре сүзләрен колакларына да элмәделәр. Сугышның азагына таба тәгәрәве сизелә, җыен гарип-гораба кирәк түгел, аларның урынын яхшы әзерлекле, җитез, уңган, таза-сау егетләр алырга атлыгып тора. Котомкасын аркасына асты да, җитмеш төрле газап белән, үткән-сүткән составларга ябышып, юл уңаена баручы машина арбаларына сыенып, ат олауларында урын табып, Гарәпша туган авылына да кайтып җитте. Аларның авыл читендә үк торган йортларында тынлык иде. Ул бусагадан кергәч тә, Шәмсекамәр, кинәт аны күрүдән югалып калды, аннан лып итеп сандык өстенә утырды да, йөзен яулык читләре белән каплап, тын гына елап җибәрде...

– Уяндыңмыни, картым, – дип дәште аңа карчыгы, ишекне шыгырдатып ачып җибәреп. Кулына табак-фәлән тоткан кебек, ярымсукыр сыңар күзе белән Гарәпша әллә ни абайламады.

– Уяндым да, тордым да. Син нәрсә, әллә төне буе егетләр янында булдыңмы? Чыгып киткәнеңне сизми дә калдым...

– Шунда, егетләр янында. Клубка чыккан идем, менә әле генә җибәрделәр, – диде карчыгы, шалтыраган табакларын мич каршына куеп. Аннан соң икенче бер савытка су агызганы ишетелде. Шәмсекамәр карты каршына килде. – Йә, суз кулларыңны. Юынабыз.

Шәмсекамәр аңа әйбәтләп юынырга булышты, битен сак кына сөлге белән сөртте. Борын астындагы тар гына мыегын, аңа кушылып киткән ияк астындагы җыйнак сакалыннан су тамчыларын сыпырды.

– Миңа ничә яшь инде, карчык? – дип сорады кинәт Гарәпша. Соңгы вакытта ул моны шаяртмыйча әйтә, чөнки, чыннан да, яшен белми саташкалый, туган елын да оныткан вакытлары булгалый.

– Сиксән сигезне тутырдың бит быел язын, әйтә-әйтә җаным чыгамы шунда?!

– Ә, алай икән... Сиңа ничә тулды?

– Җитмеш сигез.

– Һай, бигрәкләр яшь икәнсең, мин үлгәч кемгә генә насыйп булырсың инде?! – диде Гарәпша, сакал-мыекларын учы белән кымтырыклап.

– Берәрсе табылмый калмас әле, бер дә борчылма! Әйдә, табын янынарак килеп утыр, чәй эчәбез.

Гарәпша, биек сәкедән төшми генә, өстәлгә таба шуышты. Өйләре бик кечкенә иде аларның, шуңа да җайлы, ерак йөрисе юк. Мичкә терәлеп торган киң сәке белән сандык, аларның янәшәсендә үк өстәл, аннан арырак савыт-саба белән тулган сервант, киемнәрне элергә бик җайлы, ишекләре лакланган, кирәк булса ачкычка бикләнә торган шифоньер. Өч урындык, өстәл өстендә стенага эленгән түгәрәк көзге дә, ишек башындагы аятелкөрси.

Шәмсекамәр аның учына ук тавык йомыркасын тоттырды, шуны өстәл читенә сугып, Гарәпша кабыгын әрчергә кереште. Тамагы ачмаса да, яшәр өчен ашарга кирәк шул.

– Миңа ничә яшь диден әле, карчык? – Гарәпша янә әлеге соравына әллә уйнап, әллә чынлап әйләнеп кайтты.

– Әстәгъфирулла! Әллә китеп-китеп аласың инде?! Нәрсәгә шул яшең белән башымны катырасыдыр иртә баштан ук?! – Начар күрсә дә, Гарәпша Шәмсекамәренең ни рәвешле борыны җыерылып, авызы мөрелеп килүен бик аермачык күзаллады.

– «Ничә яшь?» – дип сорыйм бит мин синнән, шуңа туры җавап бирүе авырмыни?!

– Сиксән сигез! Егет чагың гына әле. Әмма ләкин туксан тугызлана башландың бугай.

– Сиксән сигез... Алай икән! Әти мәрхүм алтмыш сигез яшендә вафат булган. Димәк, миңа егерме елны өстәгәннәр, карчык!

– Нәрсә өчен өстәсеннәр сиңа?! Урының җылыда, тамагың тук. Әтигә ул бәхет тәтемәде.

– Әллә синең шәп тәрбия күрсәтүеңә озак яшим димәкчеме үзең?! Юк, хикмәт анда түгел. Егерме ел – муллалык хезмәте өчен Аллаһы Тәгалә биргән гомер...

– Әстагы, ни сөйләп ята бит?! Муллалыктан китүеңә ике елдан артык. Шөкер, әле дә исән менә, юкбар нәрсә белән башымны әйләндереп утырасың...

– Димәк, муллалык хезмәтендә эшләнмәгән эшем калган, Ходай мине шуның өчен тотадыр, мөгаен!

– Синең белән генә маташырга вакыты бар ди Ходай Тәгаләнең!

– Аның һәркемгә вакыты бар, карчык, язык сүз сөйләп утырма.

– Соң, нинди эшең калсын инде синең? Сәкедә йоклап, мин пешергәнне ашап, тыныч кына яшәп яту – менә синең хәзерге хезмәтең!

– Бернәрсә дә очраклы түгел. Әйтәм бит, әти мәрхүмнең гомере мондый озын булмады дип... Я, ярый, сиңа сүз кушкан мин юләр! Кая, таягымны бир әле, урамга чыгып әйләнеп керәм!

Шәмсекамәр карчык шунда ук, сикереп торып, җәһәт кенә картының аякларына ялтырап торган кара кәлүшләрен кидерде, арка җылысын бирде, кәләпүшен башына матурлап урнаштырды, тоткасы җайлы гына итеп эшләнгән таягын сузды. Гарәпша, каршындагы юлын таягы белән капшаштыргалап, ишеккә юнәлде. Хәер, мондагы һәрбер почмакны ул яттан белә инде. Бусаганы җиңел генә атлап чыкты, өйалдын узып, ишекне ачып җибәрде.

Ишегалды тыныч, бары тик аның ике почмагында үсеп утырган каеннар гына салмак җилдә яфракларын лепердәтеп куя. Гарәпша, башкалар төсле, йортын биек коймалар, ырыс капка артына яшермәде. Гади генә рәшәткәләр тезелгән, ул койма агачтан уеп ясалган чәчәккә охшаш бизәкләр белән ямьләндерелгән. Теләсәң, бакча диген, теләсәң – ишегалды. Сул якта янбакча бар анысы. Аннан кипкән суган кыягы исе килеп тора – Шәмсекамәр, аларны йолкып, буй-буй итеп кибәргә салып куйгандыр. Берничә төп карлыганнары да бар. Бәрәңгене инде әйткән дә юк. Аннан башка авылда тормыш бармый. Бәрәңгегә иртәрәк әле, балалар мәктәпкә киткәч кенә төшәсе.

Аякларын күтәрми диярлек шудырып атлап, ул урамга чыкты. Шушында ук артлы эскәмия тора иде. Утырды, таягын сөяде. Колагы каты булса да, үзеннән ерак түгел техника гөрелтесен ишетә ул. Урак өсте, комбайннар басуга чыгарга әзерләнә. Елның-елында шушында, кайчандыр, бик борынгы заманнарда зират булган урынга төнгелеккә кайтып туктый алар. Ул зиратка кем күмелгәнен белүче юк. Бер елны, каршы яктагы чокыр яры ишелә башлагач, ике кабер ачылды. Череп беткән агач кабык эчендә саргайган сөякләр ята иде. Кабык эченә салып күмү мөселман гадәте түгел үзе.

Дәвамы бар >

Язучы фикере

Мәзәк бабай

Өлкәннәрнең барысы да аны бик хөрмәт итә. Ә без аны, кайда очратсак та, сырып алабыз да сөйләргә кушабыз. Ул бераз карышып торган була. Без сорыйбыз, үтенәбез, ялынабыз. Һәм, ниһаять, ризалаштырабыз. Юлыбызда очрамаса, аның эш урынына, каравылга барабыз. Сөйләтми туктамыйбыз. Ул сөйли, без тыңлыйбыз. Безгә кызык. Өлкәнрәк малайлар аны бераз шыттыра дигән булалар. Дисәләр ни. Аның каравы ул кызык итеп сөйли. Без көләбез. Һәм әчтән генә соңга калып тууыбыз, ул кичергәннәрне күрә алмавыбыз өчен бераз үкенәбез. Үкенерлек тә шул. Шулкадәр кызык сугышны күрә алмыйча калганбыз ич. Андый күңелле нәрсәләр әллә тагын була әле, әллә юк. Ә ул сөйли:

– Бер мәлне разведкага киттек. Биш кеше. Ап-ак киемнән. Кыш. Кар астына чумдык та йөзеп барабыз. Ике-өч чакрым узгач, башны күтәреп карасак, немесләрне узып киткәнбез. Кире борылдык та тагы кар астына чумдык... Әй, йөзәбез, малай, әй, йөзәбез. Туктале дип калкып чыксак, кабат үзебезнекеләр янына кайтып җиткәнбез. Командир тәмәке тартып тора. Безне күрде дә бу тоз мылтыгыннан атып та җибәрде. Үзе тиргәшә: «Болай аңгыраеп йөрсәгез, бер мидал да бирми өегезгә кайтарып җибәрәм. Барыгыз, тиз генә тел алып кайтыгыз, яп-яланаяк малайлар!» – ди. Кабат карга чумам гына дип торганда, яныбызда өч нимес калкып чыкты. Болар да разведкага, тел алырга дип килгәннәр икән. Без аларны шундук борып салдык та командир алдына китереп куйдык. Әй, шатланды командир моны күргәч, шундук ашханәгә җибәрде, суган шулпасы белән сыйланырга...

Без суган шулпасының нәрсә икәнен белмибез. Тик командир тиклем командир шуның белән сыйлагач, аны бик тәмле нәрсәдер дип уйлыйбыз. Өйгә кайткач, өлкәннәрне: «Суган шулпасы пешерегез әле», – дип йөдәтәбез. Алар пешерә. Итле аш шулпасына суган салып ясыйлар икән аны. Чынлап та тәмле була икән. И-и, монысын безнең әниләр генә пешерә ич аның, ә сугышта чын поварлар пешергәне тагы да тәмлерәктер инде. Кыш җитсә, карга чумып карыйбыз. Чумуы әллә ни кыен түгел, йөзеп кенә булмый.

– Бер мәлне, малай, атакага ташландык. Җиппәрәбез генә «ура» кычкыра-кычкыра. Ике кешегә бер генә мылтык, аның да патроннары санаулы. Шулай булгач, йөгерергә җайлы. И, без йөгерәбез. Окопларына килеп кенә җиттек дигәндә, немесләр ата башлады. Ә без йөгерәбез, җиппәрәбез генә.

– Тидерә алмыйлармы сезгә? – дип сорый берәвебез.

– Тия инде, ничек тимәсен. Кораллары яхшы бит аларның, үзләре дә төз аталар.

– Тигәч, үлмисезмени?

– Үлдем дип кенә уйлап бетерәбез дә тагы тереләбез. Ул вакытта үзебез дә аңлап бетермәгәнбез инде, соңыннан гына белдек. Без үлемсез булганбыз икән. «Совет солдаты – үлемсез» дип әйттеләр соңыннан. Ярый, туктагыз әле, мин менә монда кереп чыгыйм әле... Күзгә чүп кергән кебек булды...

Ул каравылчы йортының түр бүлмәсенә кереп китә. Мышкылдаган тавыш ишетелә, бераздан тамагын кырып ала. Һәм кабат безнең янга чыга. Елмая.

– Нәрсә, шилма малайлар, һаман китмәдегезмени әле?!

– Ә кулыңны кайда өздердең? – дип сорый берәвебез. Без сискәнеп китәбез. Өлкәннәрнең болай дип сорарга ярамавын искәрткәннәре бар иде бит. Тик инде соң. Әмма аның исе дә китми.

– Өздермәдем. Үзе төшеп калган ул. Кеше күп иде, шуңа бик эзләп тә йөрмәдем инде. Җиңеллеккә болай җиңелрәк, канишны. Кайчагында уң колакны кашырга кирәк булып куя да... Ярый инде... Аны сул кул белән дә кашып була...

Бераз үсә төшкәч, без аның чынлап та шыттыруын аңладык. Һәм аның авызына карап мөкиббән киткән энекәшләребезне кисәтми калалмадык: «Ышанмагыз, алдый ул». Алар, әлбәттә, безне тыңламадылар.

Ә тагы да зуррак үскәч, аның чынлап та орденлы каһарман икәнлеген белдек. Бик каты сугышка эләккән. Бөтен ротадан берүзе генә исән калган. Яралангач та, дошман белән алышудан туктамаган. Башта аны мәетләр белән бергә тезгәннәр. Соңыннан кемдер исән икәнлеген сизеп калган да медчастька озатканнар. Бу хакта ул үзе беркайчан да бер авыз сүз дә әйтмәгән. Кемдер сөйләгән. Ниндидер читтән килгән кеше. Һәм аңа ышанганнар. Хәер, үзе дә азрак салып алган чакларында:

– Берүзем исән калдым бит. Берүзем... – дип аптырап та, әрнеп тә әйткәли торган булган. Һәм бетте, шуның белән шул.

Бу вакыйгаларга инде бик күп еллар узды. Без дә олыгайдык. Аның белән бергә яуга киткән соңгы ветераннары җирләгәнгә дә унбиш ел үткәндер. Ә ул һаман исән. Хәзер инде хатирәләрен сөйләттерергә тырышып, артыннан иярәп йөрүче малайлар да юк. Үзе дә сөйләргә бик атлыгып тормый. Тик шулай да кайбер чакларда үзен уратып алган башка заманга аптырабрак карап тора да:

– Берүзем исән калдым бит. Берүзем... – дип башын чайкап куя.

Марат КӘБИРОВ



Рәис Габдулла

18 февраль санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: тодес, изү, кәүсә, Лут, Яруллин, Ан, Әдип, ястык, тәүлек, термос, әзи, рол, байдарка, лом, кем, гүя, ыра, фал. **Вертикаль буенча:** тубылгы, рас, унтер, Мга, такыл, адәм, лактоза, кяф, Дәүли, әсир, нәхү, Камал, Ләис, Лора, Ури, дүрт, Пикуль.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 «Хәлен җуйган син бөркетkә,
Ай, син бөркеткә
Шифа бирсен изге диңгез,
Изге ул диңгез. Әй!»
Бу шигырь юлларының авторы кем?
А) Роберт Әхмәтҗанов;
Б) Таҗи Гыйззәт;
В) Фәнис Яруллин.

2 Көнбатыш Рим империясенең җимерелүе ничәнче елга карый?
А) 476;
Б) 410;
В) 378.

3 Зур террор чорында республикада ... кеше сәяси репрессияләргә эләгә.
А) 200500;
Б) 100000;
В) 54727.

4 1939 елда латин алфавитын ... алыштыра.
А) кириллица;
Б) рун;
В) латин алфавиты кала.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) В; 4) А.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 17126 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 227

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+